СӨТ БӘЯСЕ

Ни өчен халыктан түбән хакка алалар да кибеттә кыйммәткә саталар?

> 6

ДМИТРИЙ ОСИПОВ:

«Баланы дәвалаганда ата-анадан бигрәк, интернет комачаулый»

> 16

ТӘРТИПСЕЗ МИКРОФОН

Иҗат арткы планга күчте, мөнәсәбәтләр алга чыкты

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 165 (29132) | Җомга | 10 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

t.me

ТИКТОРМАС БЕНЗИН

ЯГУЛЫК БӘЯСЕ НӘРСӘГӘ БӘЙЛЕ?

Машинадан төшеп, җәяү йөрергә туры килмәгәе. Бензин бәясе кыйммәтләнүгә аптыраган «тимер ат» хуҗалары әнә шулай ди. Бүген АИ-92 маркалы бензинның бер литры 50 сумлык чиктә тирбәлә. Мондый бәяләрдән башы әйләнгән машина йөртүчеләр соңгы атналарда ил Хөкүмәте тырышлыгы белән ягулык бәяләренең бераз төшкәнен дә сизми калды кебек. Алда безне нәрсә көтә? Ягулыкның сыйфаты ни хәлдә? Бу хакта белгечләрдән сорадык.

> 5

Ишетми калмагыз

Күпбалалы гаиләләргә салым түләү буенча өстенлекләр бирергә, шул исәптән аларны керемгә салымнан азат итү мөмкинлеген карарга кирәк. Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко шулай дип белдергән. Моннан тыш, ул мондый гаиләләргә шәхси торак һәм аз катлы йортлар төзү программаларын булдырырга тәкъдим иткән. Сенатор фикеренчә, 30–40 яшьлек ир-егетләр һәм хатын-кызларга, ягъни киләчәктә бала алып кайту ихтималы зур булган гаиләләргә аерым игътибар бирергә кирәк. Валентина Матвиенко сүзләренә караганда, аларны тәрбияләүче әби-бабайларга да ярдәм итү турында уйлану артык булмас.

Татарстанда IT өлкәдә эшләүче белгечләр уртача 85 мең сум хезмәт хакы ала. Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Лотфулла Шәфигуллин әйтүенчә, республикада яшәүчеләрнең 3 проценты, тагаен әйтсәк, 42 меңнән артыграк кеше IT өлкәгә җәлеп ителгән. Төбәктә 3380 компания эшләп килә. Шуның 580гә якыны Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы аккредитациясенә ия. Башкаладагы IT парк директоры Руслан Власов әйтүенчә, хәзерге вакытта Татарстанда булган 3 технопарк (Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә) 100 процентка диярлек резидентлар белән тулы. Аның сүзләренә караганда, болар белән генә чикләнергә кирәкми.

Ял көннәрендә Татарстанда суыта. Һава температурасы нульгә төшеп, кайбер районнарда карлы яңгыр явачак.
Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, шимбә – 11 ноябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +2...+5 градус күрсәтәчәк. Төнлә 0...+3 градус тирәсе булачак. Яңгыр, урыны белән юеш кар көтелә. Төньяк-көнбатыштан секундына 6–11 метр, төнлә – урыны белән 15–17 метр тизлектә көчле җил. Якшәмбе – 12 ноябрьдә көндез һава температурасы 0...+4 градустан артмаячак. Төнлә 0...–4 градуска кадәр төшәчәк. Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, киләсе атна башында көндез +2...+7 градуска кадәр җылыта. Төнлә – 0 градус чамасы. Карлы яңгыр, көчле җил булыр дип фаразлана. Юлларда – бозлавык.

Татарстанда коронавирусның яңа штаммын – «пирола»ны йоктыручылар юк. Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, бездә ковидның «омикрон» штаммы һәм аның төрләре өстенлек итә. Аерым алганда, чирләүчеләрнең 22 процентында «кракен» ачыкланган.
Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова әйтүенчә, Россиядә «пирола» штаммын йоктыруның 10 очрагы билгеләнгән. Илдә әлеге төрнең таралу ихтималы бар.

Районнарда ни хәлләр?

Чаллы

Шәһәрдә 27 рөхсәтсез чүплек оештырганнар. Аларның 12се – Үзәк, 9ы – Автозавод һәм 6сы – Комсомол районнарында. Бу хакта «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары Илья Зуев хәбәр итте. Шәһәр мэры Наил Мәһдиев җавапсыз калмады. «Әлеге чүплекне башка планетадан килеп түкмәгәннәр бит. Шәһәрдә яшәүчеләрнең эше. Үзеңнең шәһәреңә ничек итеп чүп түгеп була икән ул?! Без яхшы булсын дип йөрибез. Ә алар... Административ-техник инспекция белгечләре мондый кагыйдә бозуларга чик куярга тиеш», – диде мэр.
(«Шәһри Чаллы»)

Зәй

Районның туган як тарихын өйрәнү музеена якташыбыз, Олимпия чемпионы Федор Симашевның значоклары һәм вымпелларын алып кайтып тапшырдылар. Аларны танылган спортчының Мәскәүдә яшәүче кызы Юлия Федоровна җибәргән. Районның Югары Баграж авылында туып-үскән Федор Симашев – Олимпия Уеннары чемпионы, 2 мәртәбә дөнья, 12 тапкыр СССР чемпионы, 5 тапкыр Универсиада чемпионы, чаңгы спорты буенча СССРның атказанган спорт остасы.
(«Зәй офыклары»)

Әлмәт

57 яшьлек хатын-кыз мошенникларга 9 миллион сумга якын акча күчергән. 2023 елның сентябрь ахырында ул мессенджерларның берсендә җиңел табыш алу мөмкинлеге турында белдерү тапкан. Эшкә керешкәнче, хатын-кызга телефонына берничә мобиль кушымта урнаштырырга һәм 100 доллар күләмендә акча кертергә кирәк булган. Үзен «финанс аналитигы» дип таныштырган кешенең сүзенә ышанып, акчасын арттыру нияте белән, 13 көн эчендә төрле банклардан алты кредит ала, берничә кредит картасын куллана һәм хәтта 2,4 миллион сумлык гаилә акчасын да юкка чыгара. Матди зыянның гомуми күләме 8,9 миллион сум тәшкил итә.
(«Әлмәт таңнары»)

Апас

Райондашыбыз, батальон командиры, майор Булат Бәдретдинов Батырлык ордены белән бүләкләнде. Ул узган елның октябрь аеннан бирле хәрби операциядә катнаша. Хезмәте буенча бронь алу мөмкинлеге булса да, Булат хәрби операциядән читтә калмады. Иң беренче сафларда ук махсус хәрби операция зонасына китте. «Улыбыз белән чиксез горурланабыз. Аны бик яратабыз. Туган ягыбызга исән-сау, җиңү белән кайтуын зарыгып көтәбез», – ди аның якыннары.
(«Апас-информ»)

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

Хөкүмәт йортында Татарстан белән Белоруссия арасындагы хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алыштылар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Беларусь Республикасының Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Дмитрий Крутой белән очрашты.

«Беларусь Республикасы – Татарстанның әйдәп баручы чит ил хезмәттәшләренең берсе. Сезнең ил соңгы елларда республикабызның тышкы сәүдә партнерлары арасында тотрыклы рәвештә лидерлар рәтенә керә», – диде Татарстан Рәисе һәм республиканың Белоруссия компанияләре белән уңышлы хезмәттәшлек иткәнен әйтте. Алар арасында «Белнефтехим», «Минск трактор заводы», «Гомсельмаш», «Амкодор», «Минск автомобиль заводы» һәм башкалар. Әйтик, хәзерге вакытта Казанда Белоруссиядә җитештерелгән 700дән артык автобус йөри. Бу – башкаладагы һәр биш автобусның дүртесе дигән сүз.

Рөстәм Миңнеханов һәм Дмитрий Крутой катнашында Казанга «МАЗ-303Т22» троллейбусларын тапшыру тантанасы узды. Яңа троллейбусларның беренчесе башкалага Республика көне алдыннан кайткан иде. Хәзер аларның саны 25кә җитте. Заманча троллейбуслар «Минск автомобиль заводы» ААҖ тарафыннан Казан өчен махсус җитештерелгән. Уңайлылык һәм иминлек ягыннан заманча таләпләргә туры килә. Троллейбуслар йомшак утыргычлар һәм гаджетлар өчен USB-розеткалар белән җиһазландырылган. Электр белән тәэмин итү өзелгән очракта, автоном система транспортка тагын 2 чакрым юл үтәргә мөмкинлек бирәчәк.

Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында «Кытай тимер юлының алтынчы корпорациясе» делегациясе белән очрашты. Үзәге Пекинда урнашкан әлеге компания тимер юл линияләре, автомагистральләр, биналар һәм коммуналь корылмалар, күперләр, тоннельләр, портлар һәм су юллары, гидротехник һәм гидроэлектр корылмалары, станцияләр, вокзаллар һәм башка объектлар төзи. Кытай территориясендәге барлык тимер юл проектларының 80 процентын артыграгын әлеге оешма гамәлгә ашырган.

«Бай төзелеш тәҗрибәгезне исәпкә алып, сезнең белән хезмәттәшлек итәргә шат булырбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Рәисе әйтүенчә, республика Кытай партнерлары белән актив хезмәттәшлек итә. Узган ел йомгаклары буенча ике арадагы товар әйләнеше күләме 58 процентка арткан һәм 1,6 млрд доллар тәшкил иткән. «Кытай бизнесы Татарстанда актив эшли: сәнәгать проектлары гамәлгә ашырыла, производстволар төзелә. Быел безнең Кытай белән элемтәләр сизелерлек активлашты», – диде Татарстан Рәисе.

***

Горбунов исемендәге Казан авиация заводында Ту-214 очкычларын җитештерү өчен өстәмә объектлар төзи башладылар. Заводта озын үлчәмле детальләр җитештерү өчен механик эшкәртү үзәге, Ту-214 самолетларына агрегатлар урнаштыру һәм җыеп бетерү корпусы барлыкка киләчәк. Яңа корпуслар төзелгән урыннарда беренче баганалар утырту тантанасында Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Моннан тыш, Татарстан Рәисе Казан предприятиесенең яңартылган музеен карады, завод территориясендәге яңа скверда миләш агачлары утыртты.

«Туполев» АҖ Директорлар советының Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган утырышында Ту-214 очкычларын җитештерүне киңәйтү программасын гамәлгә ашыру барышы турында фикер алыштылар.

ИМИНЛЕК ҺӘМ ТӘРТИП САГЫНДА

10 ноябрь – Россия Федерациясенең эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көне. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән Премьер-министр Алексей Песошин котлады.

«Татарстан Хөкүмәте исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән һөнәри бәйрәмегез – Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көне уңаеннан котлыйм, – диелгән котлауда. – 10 ноябрь күп кенә гаиләләр өчен елның иң әһәмиятле көннәреннән берсенә әйләнгән. Бу көнне эчке эшләр органнарында хезмәт иткәннәрне һәм хезмәт итүчеләрне котлыйлар.

Бүген җәмгыять сезгә зур таләпләр куя. Шәһәр-район урамнарындагы тәртип, республикада яшәүчеләрнең тынычлыгы, үз иминлегенә ышанычы сезгә бәйле. Нәкъ менә сез хакимиятне, законны, гаделлекне гәүдәләндерәсез. Эшкә карата җаваплы мөнәсәбәт белән, һәркемнең проблемаларына игътибарлы булу, ә иң мөһиме – профессиональ эш белән генә ышанычлы яулап, аны тиешле биеклектә сакларга мөмкин.

Соңгы елларда эчке эшләр органнары хезмәткәрләре җәмгыятьтә зур шау-шу тудырган кайбер җинаять очракларын ачты, коррупциягә каршы көрәш буенча чаралар уңышлы үткәрелеп килә. Республикада зур иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чараларын үткәргәндә иминлек, тәртип саклана. Татарстан Республикасында каһарманлык үрнәкләрендә тәрбияләнгән эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, үз антына һәм хезмәт бурычына тугры калып, элекке буыннарның традицияләрен алга таба да дәвам иттерәчәгенә ышанам.

Бу көнне эчке эшләр органнары ветераннарына аерым җылы рәхмәт сүзләрен җиткерәсе килә. Алар, бай тәҗрибәләре белән уртаклашып, яшь хезмәткәрләрнең үз эшенең остасы булып өлгерүенә саллы өлеш кертә, һәлак булганнарның гаиләләренә төрле яклап ярдәм күрсәтә.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы алдында бик зур дәүләт бурычлары тора. Алар сыйфатлы итеп һәм үз вакытында башкарылачак дип уйлыйм. Хокук тәртибен һәм законлылыкны саклау – һәркайсыгыз өчен гади генә түгел, ә гомерегезне шуңа багышлаган эш бит!

Сезгә һәм гаиләләрегезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!»

ӘЛӘК ТҮГЕЛ, ЯХШЫ ТЕЛӘК

АВТОИНСПЕКЦИЯ БАШЛЫГЫ ИСЕРЕК ЙӨРТҮЧЕЛӘР ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТӘРГӘ КУШТЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ел башыннан бирле Татарстан юлларында үлем-китем, имгәнү очраклары кимегән. Аның каравы юлларда теркәлгән фаҗигаләр саны арта бара. Ун ай эчендә балалар катнашындагы һәлакәтләр саны да арткан. Бу хакта Татарстан Дәүләт автоинспекциясе башлыгы Рөстәм Гарипов хәбәр итте.

Быелгы 10 айда Татарстан юлларында 2827 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 233 кешенең гомере өзелгән, 3368 кеше имгәнгән. Юл сагында торучылар чаң суга: республика юлларында балалар катнашындагы һәлакәтләр саны да арта бара. Быел әнә шундый 389 авария теркәлгән. Бу узган елгыдан 25 очракка күбрәк. Юлларда 16 баланың гомере өзелгән. Әлеге куркыныч сан былтыргыдан 5кә артык. Узган айда гына Казан, Яшел Үзән, Алабуга, Түбән Кама һәм Менделеевскида 5 баланың гомере өзелгән.

– Мондый фаҗигаләр нигездә ата-аналар гаебе белән килеп чыга. Димәк, алар баланың гомерен һәм сәламәтлеген саклап калу өчен кулыннан килгәнне эшләмәгән. Машинада барганда бала махсус кәнәфигә утырган, каешы эләктерелгән булырга тиеш. Бу яктан ата-ана үзе дә баласына яхшы үрнәк күрсәтергә тиеш, – диде Рөстәм Гарипов.

Автоинспекция башлыгы исерек йөртүчеләр мәсьәләсенә аерым тукталды. Бу хакта тиз арада ЮХИДИ идарәсенә хәбәр итәргә кирәк. Шунда ук искәртеп тә куйды: әләкләү түгел, кеше гомерен саклап калуга үз өлешеңне кертү бу.

Ел башыннан бирле инспекторлар исерек килеш рульгә утырган 11 меңнән артык кешегә беркетмә төзегән. Мондый хәлдә икенче тапкыр эләккән 911 кешегә карата җинаять эше ачылган. Ун ай эчендә республикада исерек килеш машина йөртүчеләр гаебе белән 177 юл фаҗигасе килеп чыккан. Аларда 28 кешенең гомере өзелгән, 205 кеше имгәнгән. Алда телгә алган саннарның һәркайсы узган елның шушы чоры белән чагыштырганда кимрәк. Узган елның гыйнвар – октябрь аралыгында республика юлларында исерек килеш машина йөртүчеләр гаебе белән 233 юл һәлакәте килеп чыккан булган. Аларда 84 кешенең гомере өзелгән, 301 кеше имгәнгән.

– Саннар кимесә дә, тынычланырга иртәрәк. Кызганыч, исерек килеш рульгә утырган кешеләр аркасында килеп чыккан юл фаҗигаләрен бетерә алмыйбыз әле, – дип искәртте Рөстәм Гарипов.

Җәяүлеләр дә юлларда игътибарлырак булсын иде. Ел башыннан бирле алар катнашында 803 һәлакәт килеп чыккан. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 6 очракка күбрәк.

– Юлны рөхсәт ителгән урыннан гына чыгарга кирәк. Машинаның ахыргача туктап беткән булуына да инаныгыз. Кышкы чорда юл аркылы чыкканда аеруча игътибарлы булырга кирәк. Ник дигәндә, кышын машина тиз генә туктый алмый, – дип искәртте Дәүләт автоинспекциясе башлыгы.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

	2023 елның 10 ае	Узган ел белән чагыштырганда (очрак)
Юл һәлакәтләре	2827	+19
Үлүчеләр	233	–24
Имгәнүчеләр	3368	–77

Куркыныч саннар

Уттан калмый

Быел республикада утка бәйле 4327 фаҗига теркәлгән, аларда 113 кешенең гомере өзелгән, тагын 168е җәрәхәтләнгән. Узган ел белән чагыштырганда, янгын очраклары 39га кимесә дә, һәлак булган кешеләр саны 7гә арткан. Бу хакта Татарстанның янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы Максим Трущин әйтте.

Республиканың 18 районында янгыннар ешайган. Чирмешәндә, әйтик, фаҗигаләр саны 2,3 мәртәбә күбәйгән. Янгыннар иң еш булган районнар исемлегендә Яңа Чишмә, Балтач, Зәй һәм Югары Ослан бар.

Янгында гомере өзелгән кешеләр саны 17 районда күбәйгән. Тукай районында былтыр ут эчендә 2 кеше һәлак булса, быел корбаннар саны 12гә җиткән. Алабуга, Питрәч һәм Аксубай районнарында аеруча арткан.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Бәйрәм

Минем олыгаю сәбәпчедерме, дөньялар үзгәрешеме, бу бәйрәм быел ничектер тыныч кына узып китте. Югыйсә дөньяның иң зур бәйрәме иде бит инде. Октябрь революциясе көне. Үзебезчә гади генә әйтсәк, Октябрь бәйрәме.

Бу бәйрәмгә кагылышлы хатирәләр бик күп. Иң беренчесе шулайрак бугай. Миңа салкын тигән, ютәллим. Әни сыер савучы бит инде минем, иртәнге савымын тәмамлый да, сөт ташучы машинага утырып, район үзәгенә, хастаханәгә алып төшә. Көн котсыз. Җепшек кар ява. Җил. Текә генә бер тау бар анда, бөтен машиналар шунда батып ята. Берәм-берәм этеп мендерәләр. Бот буе гына малай булсам да, әни мине дә ияртә. Алдагы машиналарны этәбез. Шуннан үзебезнекенә чират җитә. Читкәрәк чыгып туктагач, арттагы берничә машинаны чыгарырга ярдәм итәбез. Машинага кереп утыргач, шофер абый радиоалгычын куша. Анда Октябрь бәйрәменә багышланган концерт. «Ленин бабай сызган юлдан Җиңүләргә барабыз», – дип шигырь укый кемдер. Минем кечкенә башымда олы фикер уяна. Тау аша үтүче шушы юлны да Ленин бабай сызгандыр, әгәр ул сызмаган булса, без машиналарны этеп мендерә алмас идек, шунда салулап ятар идек сыман тоела.

Больницада кеше бик күп түгел.

– Яткырырга кирәк, – ди врач апа. – Кичекмәстән дәваларга кирәк. Тик бүген үк сала алмыйбыз. Бәйрәм. Октябрь бәйрәме. Барысы да ялда. Бәйрәмнән соң килегез.

Врач апа янынннан чыккач, мин әнидән сорыйм:

– Әни, ә Октябрь бәйрәмен ни өчен ноябрьдә үткәрәләр ул?

– Белмим, – дип башымнан сыйпый әни. – Шулай кирәктер инде…

Ничәнчедер класста укыганда Октябрь бәйрәменә багышланган концерт әзерләдек. Мин шигырьләрне тиз ятлый һәм әйбәт сөйли идем. Шуңа иң яхшысын миңа бирделәр. Хәниф Кәримнең «Ленин һәйкәле» дип аталган шигыре ул. Мин аны бик тырышып ятладым. Ләкин… Сәхнәгә чыккач онытттым. Теге шигырь искә төшмәде, хет концертны өземим инде дип, үзем белгәнне укырга тотындым. Яраткан шагыйрем Әнгам Атнабаевныкы иде ул. «Төш» дип атала иде. Халык яратты. Көлешеп-елмаешып тыңладылар. Бүлдереп кул чаптылар.

Хәтта хатын мактый: эчмәгәнмен,
Гуләйт итмәгәнмен – уңганмын,
Алтын кебек кеше булганмын бит,
Үлеп кенә харап булганмын, –

дигән җиренә бигрәк тә. Әле мин сәхнәдән чыгып киткәч тә алкышлар озак вакыт яңгырап торды. Бары тик укытучы апа гына якадан җилтерәтте:

– Харап иттең бит син мине… – Һәм яратып кочаклап алды. – Барыбер, маладис. Барыбер маладис…

Октябрь бәйрәме җиткән саен, мин үземнең аның кочагында чагымны искә төшерәм. Ә колагымда аның сүзләре яңгырап киткәндәй була: «Барыбер, маладис!..»

Балачак, үсмер чак, егет чак…

Башкорт дәүләт университетының рабфагында укып йөргән вакыт. Әни авырып китте. Мин аның бердәнбер баласы булгач, кайттым инде. Хастаханәгә атарга кушканнар. Ятты. Алыштырырга кеше булмагач, мин аның урынына савымчы булып эшләп тордым. Укырга килү мәҗбүри түгел иде бугай инде. Тик Октябрь бәйрәме демонстрациясендә катнашу мәҗбүри булган. Мин анда катнаша алмадым. Кабат килгәч, бик нык итеп тиргәп, рабфактан куып чыгардылар. Бер профессор агайның сүзе аеруча нык хәтеремдә калды:

– Бар, алайса, әнкәң янында ят. Колхозыңнан чыкма.

Менә шул вакытларны искә алдым да социаль челтәрләрнең берсенә: «Октябрь бәйрәме белән!» – дигән пост урнаштырдым. Бер генә комментарий килде: «Марат абый, саташтыгызмы әллә? Нинди октябрь сөйлисез? Ноябрь бит инде…»

Кайчагында бәйрәмнәр дә үлә. Кайберләре – безнең күз алдында…

Әйтеп кенә бактым

Белмим кемне аласы

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Төрле милләт халыкларының бер гаилә булып дус һәм тату яшәвенә совет чорында ук нык-лы нигез салынган иде. Бу нигез тагын да ныграк булсын өчен, интернациональ гаиләләр ко-руга галәмәт зур игътибар бирелә башлады. Без:

«Совет иле – туган йортыбыз,

Шундый иркен синдә сулавы...» – дип җыр-лый-җырлый, катнаш гаиләләр турында тапшыру-лар эшли, газета-журналларга язмалар әзерли башладык. Бу өстән кушылды. Һәм шәхсән мин, партиянең «зирәк сәясәте»н хурларга җыенмыйм. Хәтта астагылар, ягъни гади халык арасында да:

«Әллә марҗа аласы,

Матур була баласы...» – дип җырлаучылар еша-еп китте.

Интернациональ гаиләләрнең халыклар дуслы-гын ныгытуда файдасы булмый калмагандыр. Бер үк җирдә, бер түбә астында дигәндәй яшәгән ха-лыкларны бер-берен күбрәк аңларга, йола-гадәт-ләрен ихтирам итәргә өйрәткәндер. Әмма өстәл сугып кычкыру, өстән кушканны берсүзсез үтәү беркайчан да яхшы нәтиҗәләргә китермәде.

Бераз читкә киткәнем өчен гафу үтенәм, хатыным, минем тәмәке тартуымны ташлатыр өчен, ниләр генә кыланмады. Яхшылап та әйтеп карады, төрле ульти-матумнар да куйгалады. Тик максатына ирешә алма-ды. Тәмәке тартуны да үз теләгем белән ташладым мин, күңел тавышы: «Ярар, Риман дус, бу начар гадә-теңнән котыл, син гаиләңә сәламәт килеш кирәк», – дип әйтте кебек. Хатын агитациясенә бирелеп кенә ташлаган булсам, бәлки яңадан тарта башлар идем.

Совет чорында барлыкка килгән интернацио-наль гаиләләрнең кайберләре дә агитация нәтиҗәләре түгел микән, дип шикләнәм. «Айт» ди-гәнгә «тайт» дию бездә бар бит инде ул.

Чагыштырмача күптән түгел бер дустым вафат булды. Исемен язмыйм, чөнки аның хатыны, бала-лары исән, рәнҗетүем бар. Менә шул дустым рус кызына өйләнде. Бик әйбәт, бик тату яшәделәр, гаиләләрендә һәр нәрсә җитеш иде. Тик кайбер чакларда дустым, ачылып китеп: «Ни дисәң дә, үз кешеңә җитми инде», – дип әйтеп куйгалады. Мәсәлән, кайбер дини йолаларда рус кардәшләр хәмер куллана, ә бу – мөселман кешегә зур гөнаһ. Ә дустым йола мәҗлесләренең һәрберсендә утырырга тиеш. Русчасы да әллә ни түгел иде дустымның, әм-ма алар хатыны белән сүзсез дә аңлашалар иде.

Катнаш гаиләләр кору бик гомерле булып чык-ты. Яшьләрнең кайберләре «марҗаның да бар җа-ны...» дип җырлый-җырлый өйләнәләр. Минем аларны гаепләргә телем бармый, мәхәббәтне бе-ренче урынга куялар икән, пажалысты гына. Тик мине бер нәрсә борчый: нигә һәр милләт баласы үзе булып калырга теләми икән? Гаилә кормасалар да, төрле-төрле милләтләр бергә кулга-кул то-тышып, матур итеп яши алалар бит.

Башка илләрдә дә, хәтта мөселман илләрендә дә катнаш гаиләләр барлыгын күреп-ишетеп беләм. Әмма аларда төп, титуллы милләт саклансын, эреп югалмасын өчен, ирләр башка милләт кызын ала, хатын-кызның исә чит милләт кешесенә кияүгә чыгуы хупланмый. Аларда милләтләр кушылып бетүне тыя торган закон юк, әмма үзең булып ка-лырга мәҗбүр итә торган йолалар бар.

Бүгенгә әйтәсе килгән шул гына иде. Катнаш гаилә кормасалар да, һәр милләт бер-берсен хөрмәт итеп, ярдәмләшеп, кунакка йөрешеп яши ала бит.

Төрлелек үзе үк матур ул. Тукай әйтмешли: «...без туган бер җепкә бергә теркәлеп». Арага дошман кертмичә, һаман бергә яшик әле.

ВЕЛОСИПЕДНЫ СОРАРГАМЫ, УРЛАРГАМЫ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

«Татар-информ»

Табигыйдыр ки, адәм баласы нәфесе белән рәхәт-леккә омтыла: байлык-муллык тели, сау-сәла-мәт яшәүне сөя, хатын-кызның чибәренә кызы-га, авыр физик хезмәттән качарга тырыша... Мал югалтуны уңышсызлык, чирне бәхетсезлек чыганагы итеп саный. Моның өчен берәүне дә гаепләргә ярамый, әлбәттә. Үзенә чир теләсә, фәкыйрьлек теләсә, аңа гаҗәпләнер идек, акылга сау дип тапмас идек...

Шулай да күреп торабыз: кешеләр мал буенча бер-берсеннән бик нык аерыла, үзләре теләгән мул-лыкка күпчелек ирешә алмый. «Ни өчен?» дигән со-рауга, әйдәгез, Коръән хакыйкате белән җавап бирә-без. Кешенең малы ул туганчы ук аңа тәкъдир белән үлчәнгән һәм язылган. Һәм күпме генә тырышма: теләә – урла, теләә – кредит ал, теләә – алдаш, язылган-нан бер мыскал да арттыра алмыйсың. Җәмгыятьтә тигезлек урнаштырырга тырышып, социаль револю-цияләр ясау да булышмый. Революция уңышлы ки-леп чыгарга мөмкин, уңышсыз да була ала, әмма нәтиҗәсе барыбер коточкыч: тоталь фәкыйрьлек, мәҗбүри хезмәткә дучар ителү, кан белән сугарылган репрессияләр... Тарихка борылып карасак, мисалла-ры күп.

Иң яңа тарихка гына карыйк: бу гасырның икенче унъеллыгында булып узган гарәп язы бер генә илгә дә бәхет китермәде: тираннар түнтәрелде, алар уры-нына начарраклары килде. Аллаһы Тәгалә 43 нче сүрәнең 32 нче аятендә аңлатып бирә коммунизм идеяләренең тормышка ашмаслык утопия булуын: кешеләрнең бер-берсеннән өстен ителүенең хикмә-тен сөйли. Адәм балаларын тигезләргә омтылу ГУЛАГ белән тәгәлләнә: эшкә җигү өчен, илне чәнечкеле ти-мерчыбыклар белән уратып алырга туры килә. Ал-лаһы Тәгаләнең байлыкны һәркемгә мул итеп бирер-гә дә кодрәтеннән килер иде, ләкин алай эшләми. Се-рен «Шура» сүрәсенең 27 нче аятендә аңлата: һәр-кемгә киң ризык бирелсә, бозыклык таралачак. Бай гаиләләрдә баланы чын кеше итеп тәрбияләү шактый кыенга төшә: үз-үзен генә сөюче эгоистлар, бер эшкә дә ярамаган хөрәсәннәр, кәеф-сафа корып, вакытын бушка уздыручы сорыкортлар гадәттә шундый гаиләләрдә тәрбияләнә дә инде. Шуңа күрә акыллы әти, байлыгы зур булса да, балаларын узындырмый. Малның җитәр-җитмәс булуы, дөрес файдаланылган-да, чынлыкта киләчәк тормышының уңышын билге-ли. Атаклы Голливуд йолдызы Кирк Дуглас бу хакта: «Мин улларыма әйтәм: балачакта минем сездә бул-маган бер өстенлегем бар иде: котчыккыч фәкыйрь-лектә тудым. Минем югарыга үрләүдән башка бер ча-рам да юк иде», – ди.

Күрәбез: стимул-мотивация дигән нәрсәләр – авырлыклар җимеше, шуңа күрә тормыш кыенлык-ларын бәхетсезлек итеп кабул итәргә ярамый. Нәфес теләгәннәргә иярүнең һәлакәткә илтүе турында та-гын бер атаклы актер һәм режиссер Аль Пачино: «Минем әнием мин уңышка ирешкәнче үлде. Исем-дә: миңа ун яшь иде. Безнең фатир югары катта. Аста, тыкрыкта, мине дуслар урамда йөрергә чакыра. Әни мине чыгармый. Мин аңа үчегәм һәм туктамый акы-рам. Ул минем гаепләүләремә сабыр итә. Һәм шуның белән тормышымны саклап кала. Аңлыйсызмы: ул чакта урамда тик йөргән малайларның берсе дә дөньяда юк инде. Әнием төн уртасына кадәр урамда йөрүемә караганда, дәресләремне әзерләвемне телә-де. Нәкъ менә шуңа күрә мин хәзер сезнең белән монда сөйләшеп утырам», – дип искә ала.

Авырлыклардан чыгуның һәм котылуның бер генә юлы бар: тырышлык – иҗтиһад. Әмма адәм баласы күп вакыт, бәла-каза килгәндә, депрессиягә бирелә һәм хәлен начарайта. «Кеше авыруны сайламый, стрессны сайлый, стресс исә авыруны сайлый», – дип кайсыдыр атаклы психолог әйткән. Стресстан ко-тылуның бер генә юлы бар: шөкер итү. Әйе, сез ял-гыш укымыйсыз, авырлыкларга шөкер итү казаны кичерәйтә һәм юкка чыгара. Уңышка юл ача һәм бу котылгысыз. Газета укучылардан берәү, алдагы язма-ларымның берсендә теләсә нинди вазгыятьтә дә шө-кер итәргә кирәклеген язгач, социаль челтәрдә ул фи-керне гаепләгән иде. Тик ул кагыйдә минеке түгел, Аллаһныкы. «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә Галәмнәр Хуҗасы шөкер итүнең – нигъмәт арттыру ысулы, ә моңа буйсынудан баш тартуның газапларга юл ачу икәнен аңлата. Бу серне аңлаучылар уңышка ирешми калмый, чөнки Аллаһның вәгъдәсе тормыш-ка ашырыла. Кеше кагыйдәнең Аллаһтан икәнен бел-мәскә мөмкин, әмма шөкер иттеме, кыенлыклар арт-ка чигеп, уңышка юл ачыла.

Атаклы күз табибы Святослав Федоров бар иде бит әле. Аның тормышы фаҗигале рәвештә өзелде. Био-графиясе бик катлаулы, сикәлтәле, әмма һәр сикәлтә аңа трамплин ролен үти. Әйтик, 17 яшьтә аягын кисәләр. Ул болай фикерли: «Харап икән – аяк, иң мөһиме: баш исән». Соңыннан исә искә ала: «Аягым-ны югалтмасам, мин үземдә ихтыяр көче һәм мак-сатка бару сәләте тәрбияли алмас идем». Бу сүзләрдә шөкер итүнең ике ысулын күрдегез: бердән, югалту-ның зуррак булмавына шатлану, икенчедән, синең өчен кирәкле һәм мөһим булуын тою.

Аллаһ тарафыннан бары тик синең өчен генә мах-сус корылган вазгыятьтән син я дөрес файдаланасың да сынауны отасың, я төшенкелеккә биреләсең һәм гомереңнең бер өлешен яисә тулысынча оттырасың. Оттырмас өчен, Коръәнне кулланма итеп файдалану кирәк. Атаклы кешеләр тормышыннан мисалларны үрнәк итеп файдаланырга мөмкин, билгеле, әмма алар да күп вакыт, адашып, безгә ялгыш юнәлеш бирә. Аль Пачиноның бер цитатасы бар: «Балачакта мин Тәңредән велосипед сорадым, аннан соңрак аңладым: Тәңре башкача эшли. Мин велосипедны ур-ладым һәм кичерү сорый башладым». Бернинди дә-лилгә дә нигезләнмәгән гаҗәп адаштыручы фикер. Аны китереп тә тормас идем – бер татар язучысы ци-татаны бик үз иткән һәм матбугатта үз фикере итеп китерде. Урлашканда тәүбә итү һәм кичерү сорау бө-тенләй бүтәнчә башкарыла: урлаганны башта иясенә кайтарып бирергә һәм аның кичерүен сорарга, аннан соң Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәргә кирәк була. Тагын бер мөһим нәрсә бар: урлашканда кеше үзенә тәкъдир итеп язылганны гына урлый, үз малын хәрамгә әйләндерә. Сабыр һәм шөкер итсә, ул мал аңа хәләл булып барыбер керер иде. Аллаһы Тәгалә исә безне кисәтә: «И мөэминнәр, сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар үзегез кәсеп иткән гөнаһ-ларыгыз сәбәплеедер» («Шура» сүрәсе, 30 нчы аять). Ягъни гөнаһлар уңышка илтми, бәла-казага китерә.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ТИКТОРМАС БЕНЗИН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Татар-информ» / Михаил Захаров

Чыгымнар күбәйде

Казанда яшәүче Нәзилә Гәрәева – гел рульдә. Өч бала әнисенең күп вакыты төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнүче улларын бер урыннан икенчесенә йөртеп уза.

– Олы улым сәнгать мәктәбенә йөри. Уртанчысы футболга мөкиббән киткән, кечкенәсе – йөзүче. Өчесе өч төрле юнәлеш буенча шөгыльләнгәч, берсен тренировкага илтеп, икенчесен өйгә алып кайтканчы көн уза. Эшкә дә чыга алмыйм, билгеле. Балаларны шәһәр буйлап йөртү өчен генә дә атнасына уртача 40 литр бензин кирәк. Автомобиль ягулыгына атнага 2 мең сумнан артык акча китә. Ишле гаилә өчен бу бик күп, – ди күпбалалы әни.

Татарстанда ягулык-энергетика ресурсларын сак куллану һәм аның сыйфатын тәэмин итү идарәсе хәбәр итүенчә, бу атна башында республикада АИ-92 маркалы бензинның бер литрының иң югары бәясе 49 сум 40 тиен торган. Чагыштыру өчен: Идел буе федераль округы буенча әлеге күрсәткеч – 51 сум 50 тиен. 7 ноябрьгә алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда АИ-95 маркалы бензинны, күп дигәндә – 53 сум 45 тиенгә, дизель ягулыгын исә 59 сум 30 тиенгә сатканнар.

Финанс киңәшче Аяз Мифтахов әйткәнчә, бүген халыкның керемнәренә караганда, чыгымнары тизрәк үсә.

– Узган ел илдә махсус хәрби операция игълан ителгәч, ә аңа кадәр коронавирус чорында да халык акчаны артык әрәм-шәрәм итмичә, җыеп баруга керешкән иде. Быел исә кесәдәге акчаны тота башладылар. Шуңа күрә чыгымнар тагын да күбәеп китте. Ә керемнәр әллә ни артмый, – ди белгеч.

«РИА Рейтинг» мәгълүматларына караганда, Татарстанда яшәүчеләрнең уртача хезмәт хакына аена 1007 литр АИ-92 маркалы бензин сатып алырга мөмкин. Әлеге күрсәткеч буенча без – ил күләмендә 30 нчы урында. Чагыштыру өчен: күрше Башкортстан – 38, Удмуртия – 50, Чувашия – 62 нче баскычта. Мәскәүдә айлык акчага 2222 литр «92ле» ягулык сатып алырга мөмкин. Ил башкаласы, Ямал-Ненец автоном өлкәсен уздырып, исемлекнең икенче баскычында урнашкан.

Тиенләп төшә

– Ягулык-майлау материалларына бәя арту ит, икмәк кебек һәркемгә кирәкле авыл хуҗалыгы продукциясенең үзкыйммәтенә дә тәэсир итә, – ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов. – Урып-җыю эшләрендә дә, терлеккә азык әзерләгәндә дә ягулык-майлау материаллары бик күп тотыла. Аларның бәясе арткан саен, бу сөт, ашлык бәяләрендә дә чагылыш таба. Дөрес, ил Хөкүмәте берникадәр чаралар күрде. Бу, беренче чиратта, күмәртәләп сату бәяләрен йөгәнләүгә кагылды. Ягулыкны ваклап сату бәяләре дә төшәчәк, диделәр. Тик автомобиль йөртүче буларак моны сизмәдем. Бәя артканда өч-биш сумга күтәрелә, төшкәндә исә 10–20 тиенгә генә кими. Ул күз алдау гына, минемчә. Тагын шунысы да бар: ягулык-майлау материалларының кыйммәт булуы авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрнең кесәсенә суга. Бу исә табыш кимүгә китерә. Соңгы ике елда ашлыкка бәя артмый. Димәк, җирдә эшләгән кешегә моннан файда юк, авыл хуҗалыгы табышсыз булып күренә. Бу исә чәчүлек мәйданнары кимүгә, мөгезле эре терлек саны азаюга китерә. Гомумән, бәяләргә даими контроль булырга тиеш. Кызганыч, алар үсүен дәвам итә.

Ел азагына кадәр ягулык бәяләре арту инфляция күрсәткече дәрәҗәсендә сакланачак, дип фаразлый Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов.

– 2019 елдан бирле илнең эчке базарында ягулык бәяләре демпфер механизмы белән көйләнә. Ул дизель ягулыгы һәм бензинга эчке бәяләрне бер үк дәрәҗәдә саклап тоту мөмкинлеген тәэмин итә. Ягъни бәяләр артса да, алар инфляция күрсәткече дәрәҗәсеннән узмый, – ди белгеч. – Демпфер механизмы ничек эшли соң? Ягулыкка экспорт һәм эчке бәяләрне чагыштыралар да, әгәр нефть компанияләре өчен товарны читкә озату отышлырак булып чыга икән, аларга бәя аермасын бюджет хисабыннан каплыйлар. Киресенчә булса, оешмалар казнага үзләре акча түли. Соңгысы, мәсәлән, базарда нефтькә бәяләр төшкәндә күзәтелә. Тик быел Россия бюджетының дефициты артты. Шуңа күрә 1 сентябрьдән ил Хөкүмәте нефть компанияләренә демпфер түләүләрен икеләтә киметү турында карар кабул итте. Бу эчке базарда бәяләр артуга китерде дә инде. Ягъни нефть компанияләренә чимални экспортка озату отышлыракка әйләнде. Тик соңгы арада бәяләр тотрыклылануын күрәбез. Моңа ил Хөкүмәте тарафыннан бензин һәм дизель ягулыгын читкә озатуны вакытлыча тыю, демпфер түләүләрен элеккеге хәленә кайтару бәрабәренә ирештеләр.

> **Ел азагына кадәр инфляция 7–8 процент дәрәҗәсендә булачак дип көтелә. Моннан чыгып, бензин бәясе күпмегә артырга мөмкин икәнен дә фаразларга була.**

«Бүген кайгырудан файда юк»

Хәзерге вакытта тармакта вазгыятьнең тотрыклылыгын Татарстанның Нефть продуктлары белән тәэмин итү предприятиеләре ассоциациясе җитәкчесе Ирек Сөләйманов та инкарь итмәде.

– Ил Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән чаралар нәтиҗәле булды. Шөкер, бүген ягулыкка бәяләр тотрыклы. Базарда нефть продуктлары җитәрлек күләмдә бар. Барлык ягулык салу станцияләре эшли. Шуңа күрә алга таба бар да тәртиптә булачак, дип уйлыйбыз. Әйе, моңа кадәр бәяләр күтәрелде. Тик хәзер вазгыять уңай якка үзгәрде. Ел азагына кадәр нәрсә булачагын фаразлау бик үк дөрес түгел, минемчә. Әмма бәяләр артмаячак, дип уйлыйм. Бүгенге бәяләр базар шартларына туры килә. Ягулыкны күмәртәләп сату бәяләренең төшүе ягулык салу станцияләре хуҗаларына өстәмә бәя кую мөмкинлеген бирде. Без барыбыз да, шул исәптән шәхси ягулык салу станцияләре хуҗалары да, тотрыклылык яклы. Чөнки барыбыз да – шундый ук кулланучылар. Иң мөһиме, ягулыкны күмәртәләп һәм ваклап сату арасында аерма булу кирәк. Дөрес, теләсә нинди оешма табыш алу өчен төзелә. Ни генә дисәк тә, хезмәт хакларын түләргә, оешманы үстерергә кирәк. «Ягулык бәяләре тагын югары үрмәли башламасмы?» – дип алдан борчылуның кирәге юк. Бүген моннан башка да мәшәкатьләр җитәрлек, – диде җитәкче.

Кечкенә «заправка»лар куркыныч

Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә, республикада ел саен көз көне ягулыкның сыйфатын тикшерү буенча махсус айлык уза. Башкаладагы ягулык салу станцияләренең берсендә узган рейдта «ВТ» хәбәрчесе дә катнашты.

Татарстанда ягулык-энергетика ресурсларын сак куллану һәм аның сыйфатын тәэмин итү идарәсе белгечләре станциядәге ягулык төрләрен махсус савытларга агызып алды. Алга таба аларны лабораториягә озатачаклар һәм җентекле тикшерү үткәрәчәкләр. Сыйфатсыз ягулык табыла икән, бу хакта тиешле документ төзелә һәм ягулык салу станциясе хуҗаларына хәбәр ителә.

– Без ягулыкның сыйфатын даими тикшереп торабыз. Ел башыннан бирле 1,6 мең проба алынды инде. Махсус айлык кысасында гына да 80 ягулык салу станциясеннән 200дән артык проба алдык, – дип сөйләде идарәнең бүлек җитәкчесе Шамил Гомәров. – 2005 нче елларда тикшерүгә алынган барлык пробаларның 20–30 проценты сыйфатсыз дип табылса, бүген әлеге күрсәткеч 1–2 проценттан артмый. Шул ук бензинның, мәсәлән, 15 төрле күрсәткече бар. Аның берсе генә тиешле нормативларга туры килми икән, әлеге төр ягулык сыйфатсызлар рәтенә эләгә. Районнардагы кечкенә ягулык салу станцияләрендә начар ягулык сату очраклары күбрәк. Чөнки алар еш кына ягулыкны бер үк бензовоз белән ташый. Мичкәне яхшылап юып та тормыйлар. Нәтиҗәдә ягулыкка чит катнашма эләгә. Шуңа күрә исеме билгеле булган, зур ягулык салу станцияләрен сайларга киңәш итәбез. Аларга, халыкны алдап, акча эшләүдән бигрәк, намуслы исемнәре өстенрәк. Махсус айлык нәтиҗәләре ноябрь азагында билгеле булачак. Административ хокук бозулар кодексы нигезендә, Таможня берлегенең техник регламентын үтәмәгән өчен, ягулык салу станцияләре хуҗаларына еллык керемнең 1 проценты кадәр, әмма 500 мең сумнан да ким булмаган күләмдә штраф яный.

Сан

Ел башыннан бирле Татарстанда АИ-92 маркалы бензин – **3 сум 63 тиен**гә, ягъни **7,9 процент**ка арткан. АИ-95 маркалысы – **5 сум 24 тиенгә**, ягъни **8,62 процент**ка үскән. Барыннан да бигрәк, дизель ягулыгы кыйммәтләнгән. Ел башыннан бирле ул – **5 сум 33 тиен**гә, ягъни **9,81 процент**ка арткан.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СӨТ ЮЛЫ

АНЫҢ БӘЯСЕ НИЧЕК ФОРМАЛАША?

национальныепроекты.рф

Ни өчен халыктан сөтне түбән хакка алалар да кибеттә кыйммәт бәядән саталар? Төрле район һәм авылларда командировкаларда йөргән вакытта иң еш бирелә торган сорау бу. Без бер литр сөтнең авыл апасыннан, яки фермадан китеп, кибет киштәсенә менеп җиткән юлы буйлап уздык. «Сөтле бәлеш»нең иң зур кисәге белән кем сыйлана? Шуны ачыкларга тырыштык.

Җитештерү

Моның өчен без Кайбыч районының Колаңгы тимер юл станциясе бистәсендә урнашкан «СЛ-сөт» оешмасына бардык. Аның директоры Альберт Хәялиев районда өч компаниягә җитәкчелек итә. Газетаның киләсе саннарында без әлеге булдыклы эшмәкәрнең эшчәнлеге белән тулырак таныштырырбыз. Әлегә безне ул җитәкләгән өч тармакның берсе – мини-завод эше кызыксындыра.

Оешма зур түгел. 2019 елда ачылган сөт заводы тәүлегенә 2 тонна продукция эшкәртә. Әлегә бу пилот проект буларак кына бара, якын киләчәктә терлек саннарын арттырып, эшкәртүне 20 тоннага кадәр җиткерү һәм әзер продукцияне күрше төбәкләргә алып чыгу теләкләре бар. Сөтне Шушырмә авылында урнашкан «Туган як-Агро» фермасыннан алып киләләр.

Шунысын да игътибарга алырга кирәк: завод халыктан җыеп алынган сөт белән эшләми, ягъни бары тик үз чималын гына эшкәртә.

– Сыйфатлы продуктның төп нигезе – бары тик тикшерелгән, сыйфатлы сөт белән генә эшләү. Кызганыч, халыктан җыела торган сөтнең сыйфаты начар. Сөт тапшыручылар арасында намуссызлар да бар. Су гына түгел, коры сөт, хәтта тоз һәм акбурга кадәр кушу очракларын беләбез. Шул сәбәпле без бары тик үзебезнең сөт белән генә эшләргә булдык, – диде Альберт Хәялиев.

Бүген алар сөт, кефир, катык, эремчек, атланмай, каймак, сөт өсте, йогырт чыгаралар.

– Безнең өчен күләм түгел, сыйфат мөһим. Шуңа күрә сөтләргә берничи өстәмәләр, ясалма катнашмалар, үсемлек майлары, тәмләткечләр дә кушмыйбыз. Шул сәбәпле саклану вакытлары да кыска: нибары 3, 7 һәм 10 көн. Таралу географиясе дә зур түгел. Продукция якын-тирә районнар һәм Казандагы кырыклап кибеттә сатыла. Сирәк кенә булса да, Мәскәүгә дә илтәбез, – ди җитәкче.

Эшкәртү

Фермадан чыкканчы, сөттән беренчел анализ алалар. Заводка килгәч, тагын бер кат тикшерелә. Шуннан соң ул пастеризацияләнә. Чираттагы этапта сөтне маеннан аерып алалар. Аннан соң шушы ук аерып алынган майны кирәгенчә кушып, тиешле майлылыкка кадәр җиткерәләр. Бу процесс сөттән берничә төр продукт ясар өчен кирәк. Аннан соң инде әзер продуктны капларга тутыралар.

– Узган елның декабрендә чималны 37 сумнан саткан булсак, быел мартта 22 сумнан җибәрдек. Югалту – 30 процент. Ләкин бу, икенче яктан, сөтнең үзкыйммәтен киметү буенча эшләүне таләп итә. Без, мәсәлән, аллы-гөлле этикеткаларга акча сарыф итмәскә булдык. Гадәти ак савытларга үзебезнең оешманың исемен һәм продукциянең атамасын гына бастырып чыгарабыз. Соңгы вакытта майлы ризыкларга ихтыяҗ артты. Кешеләр каймак, кибет каймагын (сметана), сөт өсте (сливки), атланмайны күбрәк ала. Әзер продукцияне заказга карап эшлибез. Ягъни әгәр эремчеккә заказ күп икән, май күбрәк кала. Аннан инде без каймак ясыйбыз. Кибет каймагына заказ күп икән, сөт өстен күбрәк алабыз, – дип аңлатты Альберт Хәялиев.

Коры сөт отышлырак

Табигый чимал белән эшләүчеләрнең эш тәртибе аңлашыла. Тик аның урынына коры сөт куллануны өстен күргән сөт эшкәртү комбинатлары да бар. Билгеле, бу турыда ачыктан-ачык сөйләүче генә юк. Күпләр бу мәгълүматны әйтмәү, яшерү яклы. Шулай да без үз чыганакларыбыз аша әлеге темәны бераз белешә алдык.

– Сөт сатып, иң күп керем кертә торган вакыт – ноябрь, декабрь һәм гыйнвар. Бу – заводларда коры сөт иң күп кулланыла торган чор да. Җәен, ягъни сөт арзан вакытта алып киптереп куялар да кышын шуны файдаланалар. Монда бары тик коры сөтне эчә торган хәлгә китереп, шешәләргә тутыру турында гына сүз бармый. Барыбер күпмедер дәрәҗәдә табигый чимал да кушыла, – дип аңлатты исем-фамилиясен күрсәтмәүне сораган бер эшмәкәр.

Әңгәмәдәшебез фикеренчә, вак заводлар бу эш белән шөгыльләнә алмый, аның өчен зур күләмдә эшкәртү, махсус җиһазлар кирәк.

– Бездә сөтне үзләрендә киптерүчеләр бардыр дип уйламыйм, булса да, берничә генәдер бәлки, – диде ул. – Үзебездә җитештерелгән коры сөтнең бәясе кыйммәтрәк булганлыктан, чит төбәктән арзанрак бәядән күпләп алып кайталар. Заводлар өчен коры сөт белән эшләү отышлырак, үзкыйммәте дә арзангарак чыга. Базардагы сөт бәясенә дә коры сөт хакы зур йогынты ясый.

Сату

Алда санап узган эшләр һәм мәшәкатьләр барысы да, матур гына итеп, сөт бәясен формалаштыра. Тик, белгечләр әйтүенчә, бер литр сөт бәясенең иң зур процентын кибетләр куйган өстәмә хак алып тора. Кайбер очракларда эре сәүдә челтәрләре сөт бәясен хәтта 60–80 процентка кадәр күтәрә. Әйтик, бүген «СЛ-сөт» оешмасының 2,5 процентлы 1 литр сөт заводтан 70 сум булып чыгып китә. Сатып алучылар кулына ул бер кибеттә – 85 сум, икенчесендә – 90, өченчесендә 112 сум булып барып ирешә. Шулай итеп, комбинаттан китеп, киштәгә менеп җиткәнче, бер шешә сөт бәясе өскә сикерә дә куя.

– Ягъни без кибеткә китергән сөтне сатып алучы 5 минуттан соң 80 процентка кыйммәтрәк бәядән алып китә. Аларның да үз чыгымнары бар, ләкин «пирог» дүрт тигез өлешкә бүленергә тиеш, дип саныйм. Әгәр сөтнең үзкыйммәте шул рәвешле формалашса, кибеттә сатыла торган сөт тә арзанрак булыр һәм бәясе үзкыйммәтен каплар иде, – ди Альберт Хәялиев.

Сүз уңаеннан, «Союзмолоко» оешмасы генераль директоры Артем Белов «ТатАгроЭкспо» күргәзмәсе кысасында узган «түгәрәк өстәл»дә Россиядә сөт ризыкларына ихтыяҗ кимүен әйткән иде. Төп сәбәп – бәя арту. Аның сүзләренчә, узган ел сөт һәм сөт ризыкларына бәя уртача 18 процентка арткан, ә куллану якынча 1–1,5 процентка кимегән.

– Безнең продукцияне сатып алу кимеде, дип әйтеп булмый, чөнки безнең үз сатып алучыларыбыз бар, – диде бу уңайдан Альберт Хәялиев. – Бәлки алар бик күп түгелдер, ләкин безнең клиентлар – сыйфатлы продукциянең ни икәнен чынлап торып аңлаучылар, белүчеләр. Киләчәктә аларның санын тагын да арттыру турында уйланабыз.

Бәяләрне бер «түбә» астына кертү өчен, эшкәртүчеләр белән сатучылар арасында килешү төзеп булмыймыни? Әлеге сорауга әңгәмәдәшебез болай дип җавап бирде:

– Бу турыда әледән-әле сөйләшүләр бара, кайбер сәүдә челтәрләре белән уртак фикергә киләбез дә. Мәсәлән, «Бәхетле» кибетләр челтәре безнең продукциягә 20–25 проценттан артык хак өстәми. Ләкин кайберләре белән сөйләшү мөмкин түгел. Тик бу – базар һәм аның үз кагыйдәләре бар. Халык шул бәядән сатып ала икән, димәк, шул хакны куялар да, – ди мини-завод җитәкчесе.

Бәяләрне, бизнес һәм кулланучыларның хокукларын Монополиягә каршы федераль хезмәт контрольдә тота. Тик белгечләр кибеттәге бәяләрне йөгәнләүне, өстәмә хакны билгеле бер проценттан арттырмауны күзәтеп бетерү мөмкин түгел, дип саный.



Кибеттәге бер литр сөтнең бәясе ничек формалаша?

◄ Сату
Кибет өстәп куйган хак (наценка).

◄ Логистика
Заводтан кибеткә бару юлы. Транспорт, ягулык һәм башка вак-төяк чыгымнар.

◄ Эшкәртү бәясе
Завод төзү, җиһазлар сатып алу, персоналның хезмәт хакы, сөт һәм сөт ризыкларын эшләр өчен чимал (оеткы, шешә, этикетка, «Меркурий»да хезмәт күрсәтү, штрих-код) алу, транспорт, керем.

◄ Савып алынган сөт бәясе
Ферма төзү һәм андагы җиһазларны алу, карап тоту, төзекләндерү, терлек һәм азык сатып алу, эшчеләргә хезмәт хакы, техника, ветеринария һәм хуҗалык чыгымнары.

(«СЛ-сөт» комбинаты мисалында төзелде)

ТАРТУ КӨЧЕ

Читтә олтан булганчы, туып-үскән җирләрендә солтан булганнарны күргәч аптырау табигый. Янәсе, шәһәрдәге мөмкинлекләрне, киң офыкларны ташлап, авылга китәләрме инде? Китәләр икән. Дөресрәге, кайталар. Чөнки туган туфракның тарту көче бар. Әңгәмәдәшләребез дә шулай ди. Туып-үскән җирләрендә төпләнеп, эшле-ашлы булган яшьләрне барладык.



АЛСУ – ДИНАР

Кайбыч

Кайбыч районындагы Олы Кайбыч авылында яшәүче Алсу һәм Динар Мотыйгуллиннарның шушы көннәрдә күптәнге хыяллары чынга ашачак. Яшь гаилә районда пекарня ачып җибәрергә ниятли.

Алсу – һөнәре буенча чит телләр белгече. Чит илләрдә яшәү тәҗрибәсе дә бар. «Читтә калу мөмкинлеге була торып та...» – дигән аптыраулы карашыбызга җавап итеп, менә ни ди ул:

– Чит телләр өйрәнү хыялым иде. Чит илләрдә сәяхәт итеп, берәр кайда яшәргә калырмын әле, дип тә уйлый идем. 2007 елда район мәктәбен тәмамлап, КФУга укырга кергәндә, кире авылга кайтып яши башлармын дигән уй булмады да. 2010 елда уку йортыннан Мароккога җибәрделәр. Шунда аңладым: туган ягымнан еракта яши алмыйм икән мин. Уку йортын тәмамлагач, Сочида эшләргә дә туры килде әле. Ул чакта да туган ягымны, әти-әни, туганнарны юксындым. Үзем өчен шул вакытта, әти-әниләргә якынрак булырга кирәк икән, дип хәл иттем.

Динар белән гаилә корып, калада 8 ел яши алар. Казанда чакта иртәдән кичкә кадәр эш дип чапканнар. Шәһәрдә яшәп тә, күңел ачу чараларына, спектакльләргә әллә ни вакыт таба алмаган әңгәмәдәшләребез.

– Динарның әти-әнисенең авылда үз эшләре бар, кибет тоталар. Шуңа да атна саен авылга кайтып йөрү безнең өчен гадәти хәл иде, – ди Алсу. – Көннәрдән бер көнне Динар белән утырып сөйләштек тә, туган якка бөтенләйгә кайтырга булдык. Тәвәккәлләп, пекарня ачарга уйладык. Төзелеш эшләре төгәлләнә инде. Бу безнең гаилә бизнесы булачак. Динар, пекарня ачарга хыялым бар, дип әйтүгә, озак уйламыйча, укырга кереп, бухгалтер белгечлеге алдым. Аңа эшне алып барырга ярдәм итәргә кирәк бит. Кайбычта пекарня бер генә, ә район эчендә авыллар бик күп. Шуңа да бу эшебез файдалы булачак, дип уйлыйм. Киләчәктә инде башка камыр ризыкларын да пешерәчәкбез.

Алсу белән Динар ике бала үстерә. Авылны алар да үз итә икән. «Аларга монда бик рәхәт. Без авылдан шәһәргә укырга киткән чакта, район җирлекләрендә әллә ни мөмкинлекләр дә юк иде, кызык та түгел иде. Ә хәзер – барысы да башкача. Кайбычта спорт комплексы да, бассейн да, балалар өчен иҗат түгәрәкләре, искиткеч парклар бар. Ике як әти-әниләребез янәбызда, алар да бик шат, безнең дә күңел тыныч», – ди Алсу.

Әңгәмәдәшебезнең Сочида төпләнеп калу ихтималы да булган.

– Миңа Сочида калырга, шунда эшләргә тәкъдим булды. Динарга: «Әйдә, син дә кил, төпләник», – дигән идем шул чак. Ул исә: «Кайда тудың, шунда кирәк булдың», – дигән иде. Аның сүзләренең дөреслеген хәзер бигрәк тә аңлыйм, – ди Алсу.

БУЛАТ – ИЛНАЗ

Саба

Сабада яшәүче бертуган Вәкказовларны белмәгән кеше бармы икән?! Пекарня кибетләре, «Кәеф бар», «Чәйханә» кафелары, «Җиңел пар» мунча кирәк-яраклары кибете, «Тимербулат» мунча мичләре җитештерү – Булат һәм Илназның уртак хезмәте бу. Бар эшләре дә тәвәккәллектән, хыялланудан башланган.

Булатның эшмәкәрлек юнәлешендә тәҗрибәсе аз түгел. 2016 елда эшмәкәр булып теркәлеп, ерак араларга йөк ташый ул. Мунча кирәк-яраклары кибетен ачу теләге тикмәгә тумаган.

– Шифалы үләннәр төнәтеп, озаклап мунча керергә яратам. Сабада мунча кирәк-яраклары сатыла торган кибет юк иде. Шуңа бертуганым Илназ белән бу эшкә тотындык, – ди ул. – Бертуганың белән эшләү җиңел. Бәхәсләр дә була. Әмма уртак тел таба беләбез. Аның икътисадчы булуы да ярап куя, чөнки ул санарга, мин тормышка ашырырга хирыс.

– Шәһәргә китмәдек тә, шәһәрдән кайтмадык та без, дигәндәй, без – шушы районда туып-үсеп, үзебезне шушында таптык, – ди Булат. – Райондагы кешеләрне эш белән тәэмин итәсе килде. Биредә төпләнүнең бер сәбәбе шулдыр. Аннан, районда эшләү дә җайлырак. Барысы да – белгән кешеләр, үзебезнекеләр бит.

Вәкказовлар тәкъдим иткән кирәк-яракларга ихтыяҗ, чыннан да, була. Мунча мичләренә исә заказларны якын-тирәдә генә түгел, күрше республикалардан да алалар икән.

ИЛДАН

Балтач

– Дөресен генә әйткәндә, укыган вакытта да шәһәрдә тору авыр иде. 4 ел дәвамында атна азагын зарыгып көтеп, авылга кайтып китү ягын карый идем. Шәһәрдәге «бөке»ләргә ачу чыга иде. Авылга кайтасы килү теләге көчле булды, – ди Балтач районындагы Кариле авылыннан 23 яшьлек Илдан Закиров.

Кайберәүләр кебек: «Авылда, районда нинди эш булсын инде?» – дип зарланып йөри белми егет. Шәһәргә дә, авылга да яраклы кәсеп тапкан ул.

– Мин 5 ел тирәсе инде җиһазларны химик ысул белән чистартам. Бу эшкә дә бик кызык кына тотындым. Социаль челтәрләрдә бер видеога юлыгып, чынлап та шулай чистартып буламы икән, дип тикшереп карау өчен, махсус суырткыч сатып алдым. Шулай итеп, 5 ел буе Балтач, Арча, Саба, Биектау, Казанга хезмәт күрсәтәм. Миңа да, мине сайлаган кешеләргә дә эшем ошый, – ди Илдан.

Балтач егете, авылда яшәүнең уңай яклары санап бетергесез, ди.

– Шәһәрдә бөтен кеше дүрт дивар кысасында яши. Ә авылда ул яктан иркен, рәхәт, урамга чыгып, йөреп керсәң дә була. Авылда машина кую мәшәкате юк. Һавасы чиста, табигате матур. Шәһәрдә кая гына барсаң да, акча кирәк. Авылда барыбер икенче төрле инде. Авылларны да элеккеге авыл белән чагыштырып булмый. Хәзер уңайлыклар, мөмкинлекләр каладагы кебек, – ди Илдан.

13 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

6.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16 +
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
21.30 Новости Татарстана 16+
23.00 «ТРЮКАЧ» 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Точка опоры» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА» 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.45 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.30 Новости
07.05, 21.40, 00.10 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25, 20.30 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
12.35 «Специальный репортаж» 12+
13.00 «Есть тема!»
14.55 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.25 «Громко»
16.35, 17.35 «Сыновья скорости: Хант против Лауды» 12+
14.25, 04.00 «СНАЙПЕР. ОРУЖИЕ ВОЗМЕЗДИЯ» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Артиллерия Второй мировой войны» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «Люди Донбасса» 16+
00.05 «ДЕЛО РУМЯНЦЕВА» 12+
01.40 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
03.10 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы һәм гадәттән тыш шартларда медицина ярдәме күрсәтүдәге фидакарьлеге өчен «Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина хезмәткәре **Хөссәен** Аммар Сафаулдиин Хөссәенгә Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

***

Илебезнең машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АСТЕЙС» акционер җәмгыяте генераль директорының төзелеш буенча урынбасары **Самаренкин** Анатолий Константинович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы җинаятьчеләрне эзләү идарәсе башлыгы урынбасары, полиция полковнигы **Синцов** Михаил Юрьевич, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләренең эшчәнлеген оештыру идарәсенең полиция участок уполномоченныйлары эшчәнлеген оештыру бүлеге баш белгече, отставкадагы милиция подполковнигы **Шейнер** Климент Олегович, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлегенең өлкән полиция участок уполномоченные, полиция майоры **Шиһабиев** Фәрит Гаптелҗәмил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Яркин** Павел Александровичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы мелиораторлары коллективы һәм "Татмелиорация" траст компаниясе" ачык акционерлык җәмгыяте, әтисе
Марат Әсәдулла улы УРМАНЧЕЕВның
кинәт вафат булуы сәбәпле, «ПМК-225» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Радик Марат улы Урманчеевның авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ИСЕМЛЕ КАГЫЙДӘ

ТАТАРЧА ИСЕМ-ФАМИЛИЯЛӘРНЕ НИЧЕК ДӨРЕС ЯЗАРГА?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Насыйбулла түгел, Нацибулла дип языгыз!», «Мин – Айсолу!» «Гуссамовамы, әллә Госсамовамы?» Исем-фамилияләрнең татарча дөрес язылышына карата бәхәсләр еш туа. Һәркемнең – үз хакыйкате. Паспорттагыча калсынмы, әллә төзәтергәме? Хата җибәрмәс өчен бердәм кагыйдәләр бармы? «ВТ» хәбәрчесе татар исем-фамилияләренә бәйле сорауларга белгечләр ярдәмендә ачыклык кертте.

Ничек язылган, шулай калсын?

– Татар теле укытучысы безнең балаларның фамилияләрен Фатыйхов дип яздырырга тырышты. Ә мин: «Таныклыкларында ничек язылса, шулай калсын», – дип әйтеп тордым. Анда – Фатыхов. Документтагыча язмасаң, аннан суд аша төзәттерәсе була. Элек авыл советында 7 класс белемле белгечләр ничек теләсә, шулай язып, күпме кешегә матавык тудырган, – ди Арча районында өч бала үстерүче Гөлнур Фатыхова.

Казанда яшәүче Гүзәлия Миннахметова да фамилиясен төрлечә язуны кабул итми. Аны ничек кенә кыландырмыйлар! Миниахметова, Минеахметова... «Иремнең туганнарының ике баласы ике төрле фамилиядә йөри. Татарча Миңнәхмәтова түгел, Миннәхмәтова! Әле кайчак паспортка карап та дөрес язмыйлар» , – дип, белгечләрне игътибарлырак булырга өнди Гүзәлия.

Башкаладагы 155 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алсу Хәйруллинаның да мондый хәлләр белән очрашканы бар. Укучыларына исем-фамилияләренең ничек дөрес язылганын аңлатырга туры килә аңа.

– «Минем таныклыкта болай язылмаган», – дип, күп укучылар каршы чыга. Мәсәлән, Шайхутдинова – Шәйхетдинова, Камила – Камилә. Ләкин аңлаткач, фикерләре үзгәрә. Мондый күренешне документ биргәндә исем-фамилияләрне дөрес язып кына бетереп була дип уйлыйм, – ди Алсу Хәйруллина.

«Татарстан муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллинның исеме паспортта русча Экзам дип язылганлыгы турында ишеткән бар иде. Бу уңайдан фикерен сорап, үзенә шалтыратып алдык.

– Бозып язылганнан түгел инде бу. Заманасында русча Экзам дип тәрҗемә иткәннәр. Нигә үзгәртергә? Миңа якыннар, туганнар Әгъзам дип дәшә. Башка җиргә барсам, Экзам, диләр. Яңгырашы әйбәт, – ди Әгъзам Гобәйдуллин, бернинди дә канәгатьсезлек белдермичә. – Элек бит исем-фамилия язганда билгеле бер кагыйдә булмаган. Һәр авыл советы рәисе белән секретаре, үзләре уйлап, татар исемнәрен русчага күчергән. Үзләренчә яхшы эш башкарган алар. Татар фамилияләре – Татарстанда, ә паспорт бөтен ил, дөнья буйлап йөргәндә кирәк. Элек төрлечә язылган авыл исемнәрен төзәтә башладылар бит. Татар исем-фамилияләре буенча да билгеле бер кагыйдә кирәк.

Электрон сүзлек бар, китабы да булыр

Бар икән андый кагыйдәләр. Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина белдергәнчә, 2021 елда татар исем-фамилияләренең дөрес язылышы буенча исемлек булдырылган. Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов тәкъдиме белән башкарылган бу эш. Хәзерге вакытта аның электрон варианты Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты (ИЯЛИ) һәм Татарстан Министрлар Кабинеты сайтларында урнаштырылган. Россиядәге һәр ЗАГС хезмәткәре аннан файдалана ала. Хәзер инде хаталар булырга тиеш түгел, дип саный белгеч.

– Әлегә китап булып басылып чыкмады, әмма чыгачак. Без Марат Әхмәтов белән дә бу хакта сөйләшкән идек. Ул да хуплады. Татар исемнәренең аңлатмалы сүзлеге исә яңадан бастырылды. Бу – Татарстан китап нәшрияты белән уртак эшебез. Сабыйларга исем кушканда да кирәк ул, – ди Гөлшат Нигъмәтуллина.

Гөлшат Нигъмәтуллина белән хаталарның ни сәбәпле килеп чыгуы турында да сөйләштек. Аның әйтүенчә, элек транслитерация, ягъни бер авазның икенче телгә ничек тәрҗемә ителүенә бәйле кагыйдәләр булмаган. Шул сәбәпле, белгечләр исем-фамилияләрне ничек ишеткән, шулай язган. Исем-фамилия, әтиләренең исемнәрендә дә хаталар киткән. Мәсәлән, Гайнуллин фамилиясен алыйк. Бер очракта ул бер «л», икенчесендә ике «л» белән язылган. Үз исемнең дә өлә ничә төрле язылышы бар: Гюльшат, Голшат, Голшад...

– Ничек кушканнар, шунысы дөрес. Татарча – Гөлшат, русча – Гульшат. Исем бирүгә игътибарлы булырга кирәк, ул баланың язмышына йогынты ясый, – ди Гөлшат Нигъмәтуллина.

Хаталы икән, ничек төзәтергә?

Исем, фамилиягезне үзгәртәсегез, дөреслисегез килә икән, бу очракта аны исем кушу таныклыгы аша алыштырырга мөмкин. Моның өчен ЗАГСка барырга кирәк. Бу эш бушлай түгел, дәүләт пошлинасы түлисе. Моннан тыш, бөтен документларны үзгәртергә туры киләчәк.

Башкалар куллана алырмы?

Электрон сүзлек турында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Олег Хисамовтан җентекләбрәк сорадык.

– Чынлап та, исем-фамилия, әтисенең исемнәрен дөрес язмау проблемасы бар. Шуны истә тотып, Татарстан Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе белән килешеп, «Исем-фамилия, әтисе исемнәренең татар һәм рус телләрендә язылышы» дигән электрон сүзлек булдырдык. Бу хезмәтне безнең институт галимнәре КФУның татар белеме кафедрасы мөдире Гөлшат Галиуллина белән бергәләп башкарды. Ул – сүзлекнең фәнни мөхәррире, – дип сөйләде Олег Хисамов. – Сүзлеккә 8 мең берәмлек антропоним, ягъни 3 мең – ир-ат, 1944 хатын-кыз исеме һәм 3 меңнән артык фамилия кертелде. Моңа кадәрге сүзлекләрдәге иске, кулланышта булмаган исемнәрне төшереп калдырдык. Татарча исем-фамилия, әтисе исемнәре билгеле бер стандартка китерелде. Аларның русча варианты да күрсәтелде. Ул ЗАГС хезмәткәрләре өчен ярдәмлек булып тора. Башкалар да файдалансын өчен, аның электрон вариантын киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итәргә планлаштырабыз.

Габдрахманмы, Абдрахманмы? Асадулламы, Әсадулламы, Әсхадулламы? Үзенчә яздырырга теләгән геройларның фикеренә игътибар итәргәме, әллә кагыйдәләргә туры китереп язаргамы? Олег Хисамов редакция хезмәткәрләрен борчыган сорауларга да ачыклык кертте.

– Теге яки бу кеше белән сөйләшкәндә: «Татарча варианты болайрак, менә шулай калдырсак ярыймы?» – дип, фикерен сорагыз. Ни өчен дигәндә, аларның паспортта язылганча куярга хакы бар. Моны әйләнеп узып булмый. Әгәр ризалашмый икән, аның вариантын калдырырга кирәк. Бу очракта «Исем-фамилияләре үзләре теләгәнчә бирелде», – дип аңлатма язарга мөмкин, – дип аңлатты Олег Хисамов.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Лилия ӘСАДУЛЛИНА, Азнакай районының Илбәт авыл җирлеге башлыгы:
– Хуҗалык китапларын карап утырганым бар. Бер гаилә эчендә дә фамилияне хата белән язганнар. Соңгы елларда бик нык сизелә бу проблема. Дөресрәге, мал-мөлкәт бүлгәндә, мирас кабул иткәндә. Бер хәреф туры килмәсә дә, суд аша «бу – минем әти», «бу – минем әни» дип, туган икәнеңне раслап йөрергә кирәк. Әнинең исеме – бер төрле, ә баланың таныклыгында – икенче. Өлкәннәргә бик авыр. Үземнең тәҗрибәдә дә шундый очрак булды. Иптәшемнең отчествосы – Дагфранович, абыйсыныкы – Загфранович. Менә хәзер ничек язарга да белмибез.

Лилия ГУСМАНОВА, Әгерҗе районы ЗАГС бүлегенең элеккеге начальнигы:
– Архив документларын актарганда, әллә нинди бормалы язуларны укырга туры килә иде. «А»мы ул, «я»мы, «о»мы яки «ы»мы? Аны бит баш ватып, уйлап утырырга кирәк. Кайберләрен һич танып булмый. Гадәттә исем-фамилияләрдәге ялгышлар Татарстаннан читтә яшәүче татарларның документларында киткән. Аларга әти-әниләре саф татар исемнәре бирергә тырышкан, әмма таныклыкка язучылар аның мәгънәсен аңламаган. Хаталар узган гасырның 30–40–60 нчы елларында еш киткән. Күбесе – ЗАГСларда һәм авыл советларында эшләүчеләр хатасы. Халык аларның белеменә ышанган. Шуңа күрә үз фикерен әйтергә кыенсынган. Бәлкем, гаиләдә биш-алты бала булгандыр. Балалары, оныклары шул хаталы документ белән йөргән. «Дөрес булмаса булмас, без шулай яшәдек һәм яшибез», – диючеләр бар. Әмма барыбер бер очы чыга бит аның. Милек проблемалары туганда, әби-бабайлар ЗАГСка ярдәм сорап килә. Без хәл итә алмыйбыз, судка барыгыз, дип аңлата идек. Алар шаккатып карап тора. Кассадан киткәндә, акчагызны ничек саныйсыз, язуны да нәкъ шулай укырга кирәк. Исем, фамилия, әтиегезнең исеме... Менә бу өч сүз кешене гомер буе озатып бара. Шуңа күрә һәр хәрефе дөрес булсын. Хәзер белгечләр документ нигезендә генә эшли, сүзгә карап кына язмыйлар.

ГОМЕРЛЕК БҮЛӘК

Чәч бөртегеннән дә нечкәрәк җеп белән, микроскоп ярдәмендә якынайтып ясалган уникаль операция! Республика балалар клиник хастаханәсенең йөрәк-кан тамырлары хирургиясе бүлеге табибы, медицина фәннәре кандидаты Дмитрий ОСИПОВ шушы батырлыгы өчен Россиянең рекордлар китабына кертелде. Әлеге катлаулы операция ярдәмендә бер айлык сабыйның кулын саклап калган ул. Дөньяда мондый уникаль операция нибары 14 тапкыр гына ясалган. Алтын куллы белгечнең уңыш сере нидә? Балалар табибына нәрсә комачаулый? Әлеге һәм башка сорауларга җавап табу өчен, «ВТ» хәбәрчесе рекордсмен табиб бүлмәсенә юл алды.

:: Дмитрий Владиславович, сөйләшүебезне сабый баланың кулын саклап калуга ирешкән мизгелне искә төшерүдән башлыйк әле...

– Бу – безнең эш тәҗрибәсендәге икенче уникаль очрак. Икесе дә Россиянең рекордлар китабына кертелде. Беренчесен 2017 елда ясарга туры килде. Ул вакытта 2 ай да 8 көнлек кыз баланың кулын саклап калдык. Аның сул кулының терсәктән бөгелә торган өлешендә шеш пәйда булган иде. Тикшерә торгач, аневризма (тукымаларның тартылуы һәм юкаруы аркасында, кан тамырларының тышка бүлтәеп чыгуы) барлыгы ачыкланды. Аневризма – бик хәтәр авыру, ул күзәтелгәндә һәр секунд исәптә. Ник дигәндә, андый вакытта кулдагы кан йөреше начарлана, тромб барлыкка килеп, ул теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин. Ахыр чиктә, баланың кулы бөтенләй эшләүдән туктап, аны кисәргә үк туры киләчәк.

Быел тагын бер катлаулы операция ясарга туры килде. Сентябрьдә безгә 1 ай да 9 көнлек нарасыйны алып килделәр. Августта гына туган, әмма анализлары начар булу сәбәпле, аны шактый вакыт стационарда дәвалаганнар. Өйгә кайткач, әнисе баланың кулыннан анализ өчен кан алган җирдә шеш барлыгын күреп ала. Шешнең торган саен зурайганын күреп, участок педиатры баланы безгә җибәргән. Кызчыкның уң иңбашы артериясендә аневризма икәнлеге ачыкланды. Һәр ике очракта да операцияне чәч бөртегеннән дә нечкәрәк җеп белән микроскоп астында зурайтып ясадык. Бу очракта башкача мөмкин түгел. Олы кешенең иңбашындагы кан тамыры киңлеге – биш миллиметр чамасы, ә сабыйныкы – бер миллиметр, операция ясаганда ул тагын да тарая. Шушы уникаль очракларның икесе дә Россиянең рекордлар китабына кертелде.

Иң гаҗәпләндергәне шул: дөньяда кул-аякларның кан тамырларында аневризма белән тууның нибары 45ләп очрагы теркәлгән. Ә нәкъ менә иңбаш артериясендәге аневризманың 14 очрагы билгеле. Дөньяда мондый диагноз аркасында катлаулы операция кичергән иң кечкенә балага алты ай булган. Аны Америка табиблары коткарган. Ә без операция ясаган балалар нибары ике һәм бер айлык кына иде. Шуңа күрә дөньяда табиб ярдәмендә куллары саклап калынган иң нәни пациентлар бездә булып чыга.

:: Моңарчы андый катлаулы операцияләрне Мәскәү, Санкт-Петербургта гына ясыйлар иде кебек...

– Элегрәк дөрестән дә шулай иде. Бәхеткә, хәзер мондый катлаулы операцияләрне курыкмыйча үзебездә дә ясап була.

> ДРКБда моның өчен иң алдынгы, заманча технологияләр бар. Табибтан да күп нәрсә тора. Мондый операцияне теләсә кайсы хирург ясый алмый. Шәхсән үзем бу эштә яшь чакта ук алган белемнәрем ярдәм итте.

Балалар хирургы белгечлегенә укып чыксам да, ординатурада чакта зурлар хирургиясе бүлегендә эшләдем. Бәхетемә, шунда атаклы кан тамырлары хирургы Сергей Обыденнов белән таныштым. Аның киңәшен истә тотып, Мәскәүгә барып, Россия медицина академиясенең бик кечкенә кан тамырлары хирургиясе юнәлешендә укып кайттым. Анда микроскоп астында кан тамырларын тегәргә өйрәндек. Ул чакта бу алым белән операция ясауның кайчандыр кирәге чыгар дип кем уйлаган.

:: Беренче операция ясаган көнегезне хәтерлисезме?

– Әлбәттә, хәтерлим. Һәр яшь хирург кебек үк мин дә беренче операцияне сукыр эчәгенә ясадым. Өлкән яшьтәге кеше иде ул. Беренче операция ясаганда ничек дулкынланганым, кулларның калтыравы әле дә истә. Хәер, бәлки беренче чиркангыч хирургия бүлегендә медбрат булып эшләгәндә үк алынгандыр. Эш арасында табибларның операция ясаганын карарга бара идем, кирәк чакта булышып та тордым. Беренче операциямне, бәлки, шул чорда ук ясаган булганмындыр әле.

Яшь табиб буларак эшли башлаганда җаваплылык зур, эш күп, хезмәт хакы аз кебек тоела. Еллар узган саен үз эшеңнән рухи канәгатьлек алуның күпкә мөһимрәк икәнлеген аңлыйсың. Әнием гомер буе балалар табибы булып эшләде. Иртәдән кичкә кадәр аягөсте эшләп, кичен кәгазьләр тутырып утыра иде. Ул минем дә табиб булуымны теләде. Тормыш иптәшем Илсөя дә – табиб. Ул ДРКБның онкогематология бүлеген җитәкли. Шушында эшләгәндә таныштык.

:: Эшләү дәверендә иң истә калган очрак та бардыр?

– Кан тамырындагы шеш (гемангиома) балалар арасында элек-электән иң киң таралган чирләрнең берсе санала. Хәзер аны төрле дарулар, лазер ярдәмендә дәвалап була. Ә мин эшли башлаган гына елларда мондый мөмкинлекләр юк иде. Гөнаһ шомлыгына, миңа ярдәм сорап килгән иң беренче баланың башында нәкъ менә шундый зур шеш пәйда булган иде. Карап торышка нәкъ әкияттәге Чиполлино инде менә. Шешне алып, чәч астындагы тирене тарттырып, ул чакта да катлаулы операция ясарга туры килде. Бәхеткә, бар да уңышлы чыкты. Әмма гомергә истә калырлык булды ул.

:: Тормыш алдан-гөлдән генә тормаган кебек, табибларның да хаталанган, уңышсызлыкка тарыган чаклары буладыр. Андый чакларда ничек тынычланасыз?

– Андый чаклар да була, билгеле. Теләсә кайсы авырудан соң күпмедер дәрәҗәдә өзлегү була. Әйтик, шул ук сукыр эчәгенә, бусергә ясалган операцияләрдән соң да еш күзәтелә ул. Монда табиб кына гаепле дигән сүз түгел. Күп нәрсә кешенең организм үзенчәлекләреннән дә тора. Эшләмәгән кеше генә ялгышмый. Хаталанган чакларда күңелгә бик авыр була, билгеле. Кулдан эш төшә. Әмма борчылуымны сиздермәскә тырышам. Күп әйбер эчтә кала. Андый чакта игътибарны башка нәрсәгә юнәлтергә тырышам. Балыкка, ауга йөрергә яратам. Бу шөгыльләрем эмоциональ «яну»дан да саклый.

:: Әти-әниләр баланы дәвалауга комачаулаган очраклар да буламы?

– Баланы дәвалаганда ата-анадан бигрәк, интернет комачаулый хәзер. Үзләре исәптә торган сырхауханәдән безгә килергә юллама алуга, кайбер ата-ана, интернетка кереп, авыру турында тулы мәгълүмат тупларга тотына. Шунда язылганнарга ышанып, баланы үз белдеге белән дәвалаучылар да очрый. Кайберләре, артыгын укып ташлап, монда килгәч, безне өйрәтергә тотына.

> Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, ата-аналарга мөрәҗәгать итәсем килә: интернетта язылганнарга ышанырга, баланы анда өйрәткәннәр буенча дәваларга ярамый! Бу махсус белеме, тәҗрибәсе булган табиб белән киңәшләшеп кенә эшләнергә тиеш. Бәхеткә, андый ата-аналар күп түгел. Күбесе безнең фикер белән исәпләшә, кушканнарны төгәл үти.

:: Соңгы егерме ел эчендә балалар, аларның ата-аналары үзгәрдеме?

– Юк, әллә ни үзгәреш сизелми. Хәзер балалар иркәрәк, ата-аналар артык хәвефле, кайгыртучан дигән фикерне еш ишетергә туры килә. Әмма шәхсән үземнең эш барышында андый хәлне күзәткәнем юк. Һәр икесе арасында да төрлесе бар һәм алар элек тә очрый иде, хәзер дә бар.

:: Балалар арасында хәзер кайсы авырулар аеруча еш очрый?

– Соңгы арада лимфангиома, гемангиома (кан тамырларындагы шеш төрләре. – **Ред.**) кебек тумыштан килгән кан тамыры авырулары аеруча еш очрый. Бәхеткә, алда телгә алган аневризма очраклары бик сирәк күзәтелә. Әмма без аларына да әзер торырга тиеш. Без күбрәк балаларда тумыштан килгән кан тамыры авыруларына каршы көрәшәбез. Мондый авыруларны булдырмас өчен, ата-аналар сәламәт яшәү рәвеше алып барырга тиеш. Дәвалау нәтиҗә бирсен өчен, ата-ананың табибка комачауламыйча, аңа ышануы да кирәк. Бу – уңышның яртысы.

➤Узган ел Республика клиник балалар хастаханәсендә 43 меңнән артык бала дәваланган. Шуларның 3 меңгә якыны яңа ачылган Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә шифа алган. Балаларның сәламәтлеген кайгырту белән беррәттән, табибларның тормышында гадәттән тыш хәлләр дә еш булып тора.

➤2022 елның декабрендә Республика балалар клиник хастаханәсенең Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә беренче тапкыр җелек күзәнәкләрен күчереп утырту буенча тәүге катлаулы операция ясалды. Моңа кадәр андый операция Мәскәү һәм Санкт-Петербург клиникаларында гына ясала иде. Операция октябрь аенда яман шеш диагнозы белән хастаханәгә эләккән малайга ясалган. Операция уңышлы чыккан.

➤Узган елның сентябрендә Республика балалар клиник хастаханәсе һәм Республика клиник хастаханәсе табиблары 17 яшьлек үсмернең өзелгән кул чугын кабат тоташтырып кую буенча катлаулы операция ясады. Үсмер, утын ярган чакта, балта белән кулын чабып өзгән. Табиблар егеткә өч катлаулы операция ясаган. Үсмер егет хәтта кул бармакларын кыса ала башлаган.

Әңгәмәдәш – Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РӘЗИНӘ ГАЗИЕВА:

«ҖИТӘКЛӘП ЙӨРЕРЛЕК ЯРЫМ БАР»

Аларны бер белдерү таныштыра. Рәзинәнең дусты Марат улына яр эзләүче хатынның хәбәрен күрә дә бу хакта аңа җиткерә. Кыз башта куркып та кала. Әгәр, башка танышулардагы кебек, кимчелеген күреп, йөз чөерсәләр? Әмма Рәзинә тәвәккәлли, белдерүдә күрсәтелгән номерга смс юллый.

– Бу номер егетнең әнисенеке икән. Башта аның белән языштык. Ул миңа шундук ошады. Икенче көнне Айнур белән аралаша башладык, – дип сөйли Рәзинә. – Шушы елның апрель ае иде бу. Булачак ирем Айнур – Башкортстаннан. Ул Казанда яши һәм эшли иде. Безне бергә итәр өчен, иремнең әнисе бик тырышты. 9 майга Казанга кунакка килеп, мине үзләренә чакырды. Айнурга әйтеп тә тормадык. Янәсе, сюрприз ясыйбыз. Такси белән Казанга юл тоттым.

Булачак каенанасы Гөлназ аны бик көтеп ала. Айнур исә, Рәзинәне күрүгә, әллә нишләп китә. Кулындагы су шешәсен дә төшереп җибәрә.

– Элегрәк егетләр белән танышкач, аларның әти-әниләре, йөри алмавымны күреп ошатмыйлар иде. Үпкәләтүчеләр дә күп булды. Дөньяга шулай килүемдә минем бер гаебем дә юк бит инде. Туганда табиблар имгәткән мине. Умырткалыгыма зыян килеп, нерв күзәнәкләре кысылган. Әмма сәламәт кеше моны аңламый. Шуңа да, әти-әнисе ни әйтер, дигән уй бик куркытты, – ди Рәзинә. – Айнурның да физик мөмкинлеге чикләнгәнлеген белә идем инде. Ул авырлык белән булса да йөри, сөйләмендә кимчелек бар. Мин исә кеше ярдәменнән башка йөри алмыйм. Тотынып кына йөрим. Җитәкләп йөртүче кирәк. Аның каравы сөйләмем яхшы. Бер-беребезгә туры килдек инде. Беребез дәшми, икенчебез сөйли. Мине Айнур тотып йөртә.

Балтач кызы – гаиләдә иң олы бала. Әти-әнисенең аны бик гаиләле итәсе килә. Айнур белән танышканын белүгә, әнисе фотосын күрә дә, кияү безнең якка охшап тора, ди. Айнур да эшне озакка сузмый. Июль аенда Балтачка кайтып, кызның кулын сорый, бер атнадан никах укытып куялар. Яшьләр Арчада яши башлый.

– Мөстәкыйль буласым килеп, 9 нчы сыйныфны бетергәч, Арчага юл тоттым. Социаль белем бирү академиясенә укырга кердем. 2015 елда юридик факультетны тәмамладым. Әмма эшкә алучы булмады инде. Баштарак кешеләргә курс эшләре язып акча эшләдем. Шигырьләр язам. Социаль челтәрләрдә 35тән артык җырым бар, – ди Рәзинә.

Ире Айнур Казанда йөк ташучы булып эшли икән. Өйләнешкәч, ул Рәзинә янына Арчага күченгән. Алар фатирга кереп яшиләр.

– Әлегә кайтып-китеп эшләп йөри. Киләчәктә үз куышыбызны булдырасы килә. Инвалидлык буенча тиеш түгелме соң, диләр. Яшебез туры килми. Сорашып карадык инде. Алга таба ничек тә фатирлы булырга иде. Әле бит безнең бәбиләр дә үстерәсе бар. Бик тә сабый сөясе килә, – ди Рәзинә.

Аларның икесенә дә – 28әр яшь. Рәзинә үзен бик бәхетле итеп тоя. Үзе әйтмешли, җитәкләп йөртүчесе бар аның хәзер. Бер дигән каенанасы да бар. Киленен үз кызы кебек якын итеп тора, улы бәхете өчен барысына да риза ул!

Алар өчен мөмкинлекләр чикләнмәгән. Башкортстан ерак дип тормаганнар, бер ай элек Илеш районының Яркәй авылында гөрләтеп туй уздырганнар. 70ләп кунак җыелган. Туйны Чаллыда яшәүче тамада Гөлназ Гайсина алып барган. Инде бер ай вакыт узса да, ул әле дә андагы кичерешләр белән яши.

Егет белән кызны кунаклар басып каршы ала. Алар бер-берләрен тулыландырып, берсе егылмасын өчен икенчесе тотып атлап килгәндә, кунаклар елый ук башлый. Алып баручының да күңеле тула. Инде нишләргә? Рәзинәнең күлмәк итәкләрен күтәреп, урындыкка утыртучы Айнурны күрүгә, Гөлназ тиз арада уен-көлке белән, эшне җайлап җибәрә.

– Ахырдан торт алып чыктылар. Ир белән хатын аны кисәргә тиеш. Күрәм: шул чакта өстәл тәгәри. Айнур нишләргә белми. Өстәл Рәзинәне егачак бит! Кунаклар сизмәсен дип, өстәлне үз гәүдәм белән тотып тордым. Шушы вакытта ир-ат буларак Айнурның кайгыртучанлыгы сөендерде, – ди Гөлназ.

Бәхетнең зуры инде бу! Гөлназ әйтмешли, мондый кешеләр гайбәттән дә ерак, күңелләре саф аларның. Алар дөньяны ихластан ярата.

– Язмышка бик рәхмәтлемен, – ди Рәзинә. – Насыйп ярын очратып, гаилә корып яшәү – һәр кызның теләге. Инде хәзер бәхетебезне саклап яшәү безнең кулда. Сөенеп яшәргә язсын!

ӨМЕТЛЕ СҮЗ

Равил Насыйбуллин белән еш очрашабыз. Теләче районының Иске Җөри авылында мәдәният йортын җитәкли ул. Әллә каян якын итеп эндәшеп тора үзе. Йөзендә гел елмаю була. Күпме генә аралашсак та, 43 яшьлек ирнең зур сынаулар узып, куркыныч авыруны җиңгәнен белми идем.

– Моннан 7 ел элек килде ул сынау. Кинәт авырып киттем. Тамагым шешкәч, башта мин моны ангина дип уйладым. Табибка да күрендем. Узар да китәр кебек иде. Тик бераздан хәлем авырайды: муеным һәм башымның шешүе куркуга салды. Теләче табиблары Казанга юллама бирде, – дип искә ала Равил. – Башкала табибы сөенечле хәбәр әйтмәде. Миндә яман шешнең дүртенче стадиясе ачыкланган икән. Сиңа операция ясап булмый, химия терапиясе бирә алмыйбыз, өйдәгеләреңә дә әйт, якыннарың белән хушлаш, диде. Кыскасы, өмет калдырмады. Шөкер, шул чакта Аллаһы Тәгалә минем юлыма коткаручы фәрештә җибәрде.

Фәрештә дип ул табиб Рөстәм Сафинны атый. Тәҗрибәле белгеч Равилгә күңелен төшермәскә киңәш итә. Баксаң, шул көннәрдә Казанга төрле илләрдән онкологлар җыелып, нәкъ менә Равилнекенә охшаш диагноз турында фикер алышачаклар икән. Табиб аны тикшеренүдә катнашырга күндерә.

– Өйдәгеләргә берни сиздермәдем. Тамак шешкән дә башка органнарга ялкынсыну киткән, дип ялганладым. Хастаханәгә ятмыйча булмый, дип кисәтеп тә куйдым, – ди Равил. – Беренче химияне 9 сәгать алдым. Рөстәм Сафин һәрвакыт янымда булды. Табиб кына түгел, көчле психолог та әле ул. Яшисең килсә, начар уйларга бирелмә, авыру кешенең сихәтләнүе 75 процент үзеннән тора, диде. Мин ышандым һәм «яшим» дидем. Авыр чакта да елмаерга тырыштым. Сер бирмәдем.

Ул хәтта үлемгә дә әзер була. Бурычлары булуы гына тынгы бирми аңа. Ул чакта бер эшеннән киткән, әле мәдәният йортына яңа урнашып йөргән чагы була. Алган кредитын кем түләр дип борчыла ул. Нурланыш, химия терапияләре алганнан соң Равилгә инвалидлык бирәләр. Шуннан соң ул беренче эш итеп, булган кредитларыннан котыла.

– Әтием сизенде. Көчле дарулар эчә башлагач, тән авырлыгым артты. Инвалидлык бирелгәч тә, нидер яшерәсең, диде. Әллә берәр документымны күргән инде ул – анысы билгесез. Әтидән бу хакта сорый алмыйча калдым. Үпкәсендә начар чир табылып, арабыздан китте. Әтине югалту тормышның якасына ныграк ябышырга мәҗбүр итте, – ди Равил.

Равилнең авыруын соңрак бөтен кеше белә. Матди ярдәм булсын дип, бер төркем татар эстрадасы җырчылары хәйрия концерты да үткәрә. Равил үзе белми дә кала. Әмма бүген ул тормышында очраган, авыр чакта булышкан һәркемгә рәхмәтле.

Гармунда да өздерә ул, җырлый да, театрда да уйный. Үзе җитәкләгән иҗат коллективы белән кая гына йөрми алар. Хәтта Россия күләмендә узган чараларда да катнашалар.

– Мин авыруны Аллаһы Тәгалә һәм ак халатлы фәрештә Рөстәм Сафин ярдәме белән җиңдем. Елмаерга, уен-көлке сөйләшергә тырыштым. Бер палатада яткан егетләр, үлдебез инде дип, гел боектылар. Алар исән түгел инде. Гел табибларга күренеп торам, вакытында анализлар тапшырам, – ди ул. – Бөтен авыру артык борчылудан килеп чыга. Шуңа да юк-барга борчылмаска киңәш итәм. Кешеләр белән аралашып яшәгез. Мәдәният өлкәсендә эшләвем белән бәхетле мин. Эшем күңелемә рәхәтлек бирә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЧЫГАРЫП СЕЛКҮ

ОЯТ БЕЛӘН ПИАР АРАСЫНДА ЧИК БАРМЫ?

Уйлап карасаң, ул кадәр күп вакыт та үтмәгән. Әле кайчан гына артистка, укытучы кебек үк, ышану бар иде. Алар халыктан өстәрәк тоела, ихтирам да, игътибар да зур иде. Күз ачып йомган арада күтәртмәдәге (хәзер сәхнә дип әйтсәң дә килми инде) хәлләр үзгәрде дә куйды. Иҗат арткы планга күчте, мөнәсәбәтләр алга чыкты. Ике артистның җыр бүлешүе гадәти хәл кебек кабул ителә башлагач, яңа «фишка» таптылар. Халыкка күрсәтеп, зур реклама кампанияләренә әйләндереп, аерылыша-кавыша башладылар.

«Татар-информ» / фото безгә өчен бирелде

И тәмләп башкаралар да соң бу эшне! Халыкка да кызык: сериал карагандай социаль челтәрләрне күзәтеп баралар, ул арада ике лагерь барлыкка килә. Шуннан «бывший муж» яклылар «бывшая жена» яклыларга каршы сүз көрәштерә башлый. Мәйданнарга ук чыгып көрәшмиләр инде, берсеннән-берсе ялкынлырак комментарийлар гына ыргыталар. Аннары тыналар. Кызык булмый башлый. Ну кызык итәргә кирәк бит инде дөньяны. Аның өчен тагын нәрсәдер уйлап табарга кирәк. Ришат Фазлыйәхмәтовка рәхмәт инде, халыкка «хеппи-энд» бүләк итте. Бераз аерылышып торганнан соң, «бывший» хатыны – Тәтишкасы белән кабат кушылды. Вәт, малай, китте бит хәлләр, Ришат яңадан телгә керде. Әмма… Кемнең ничектер, миңа, Ришат, дигәч, бер җыры да искә төшми, ә менә Тәтишкасы күз алдына килә.

Баштарак җырчыны җыры аша таныйлар иде. Шәхсән минем, Салават концерт куя, дисәләр, «Абый, абый, Салават абый…» – дип сузып җибәрәсе килә, «Салкын чәе», «Уфтанма»сы, «Сандугач керде күңелгә»се искә төшә. Зөлфәт Хаким, дисәң – «Нәрсә булды синә бүген?», Хәмдүнә, дисәң – «Җомга», Зәйнәп дисәң, Зөфәрә белән җырлаган «Ак майларда ак вагъдәләр»е искә төшә. Тавышларын да, кыяфәтләрен дә, җырларын да, үзләрен дә бутый торган түгел. Хәзер бар да бер-берсенә охшап бара. Ясалма ирен, ясалма күкрәк, ясалма көчәйтелгән тавыш, ясалма мөнәсәбәтләр…

Ярый әле, бу дөрес хәл түгел, дип әйтүчеләр бар. Күп түгел инде алар, алай да бар. Юкса, тормыш та ясалма тоела башламагае, дим. Эстрада профессоры Салават ФӘТХЕТДИНОВ андый «пиар»ны үзенә дә тәкъдим иттеләр ди:

– Дөрес юл түгел бу. «Кара пиар» безнең милләткә килешле нәрсә түгел, башкалар артыннан куып, үз асылыбызны югалтырга ярамый. Кызганыч хәлләр. Телебез – татар, динебез ислам булгач, ә бездә халыкның дингә йөз белән борылган чагы, гаилә эчендәге хәлләрне халыкка чыгарып селкергә кирәкми. Димәк, ул кешенең үз фикере юк. Бу – беренчедән, күзгә карап алдашу, икенчедән, ирлегеңне түбән төшерү. Әле бит: «Нишлим, дуслар?» – дип, аптырап язып утыралар. Синең аерылганыңда яки кушылганыңда минем ни эшем бар? Минем үз гаиләм бар, үз мәшәкатьләрем җитәрлек. Шуны оялмыйча, ир-ат башы белән, мескенләнеп халыкка чыгарып селки. Миңа да тәкъдим иттеләр: популярлыкка ярдәм итә, кирәк, диделәр. Андый популярлык төн чыкканчы бетә ул. Ә мондый арзанлы адымга баручылар – динен, денен югалтучылар.

Алай гына да түгел. Оят гамәл икән әле ул. Рамил хәзрәт ЮНЫС шул фикердә:

– Көнбатыш илләрендәге агымга ияреп, үзләренең тормышларындагы негатив хәлләрдән файдаланырга тырышу, реклама ясау дингә дә, әдәп-әхлакка да туры килми. Беренчедән, аерылу ул – шуның кадәр оят гамәл. Син үз дәүләтеңне (ә гаилә ул – дәүләт) тота алмагансың, җимерелергә ирек куйгансың дигән сүз бит инде. Әйе, монда гаеп атта да, тәртәдә дә була. Икенчедән, пәйгамбәребез, Аллаһы Тәгалә иң яратмаган эш ул – аерылу, ди. Аллаһның яратмаган эшен бөтен дөньяга чәчеп йөрү ул бернинди кануннарга да сыешмый.

Тормышка интернет килеп кергәч, бөтенебез артист, сценарист, пиарщик, рекламщик булып беттек бугай. Алда безне нәрсә көтә, алай булгач? Татар Малай тәхәллүсле беренче татар блогеры Ренат ГАЛИӘХМӘТОВ бу күренешләрне вакытлыча дип атый:

– Үзең уйлап тапканга караганда күчерү һәрвакыт җиңелрәк. Бу күренешләрне мин Көнбатыш шоу-бизнесыннан, рус шоу-бизнесыннан күчерү дип атар идем. Бу – була торган хәл, аны тыеп та, аннан тыелып калып та булмыйдыр. Әмма чикләр булырга тиеш. Кайберәүләр мөнәсәбәтләрен халыкка күрсәтеп, кичерешләре белән уртаклашып, күңелен бушата. Миңа авыр, дип, теләктәшлек итүләрен көтәләрдер бәлки. Ә менә өйләнешү, аерылышулар – алары 100 процентлы пиар инде. Әмма бу – икенче сортлы, артистның дәрәҗәсен төшерә торган пиар. Миңа бу очракта халыкның мөнәсәбәте ошый. Ул шунда ук ялганны сизеп ала да, комментарийда, нишләп алдыйсыз, дип яза. Миңа да әйтәләр: югалыбрак калдың, батллар оештыр, диләр. Мин үз сәхифәләремне ничек алып барам – шулай алып барам инде. Кемгәдер «Пусть говорят» кирәк икән, аны үз битләрендә ясасын. Безгә андый статистика, андый пиар кирәк түгел. Безнең гаиләдә дә төрле хәлләр була. Ләкин ул ике кеше арасында гына калырга, без үз проблемаларыбызны үзебез хәл итәргә тиеш.

Икенче сортлы, дигәннән. Язучы Марат КӘБИРОВ та социаль челтәрләрдәге кавышу уеннарын чикләнгәнлек нәтиҗәсе дип атый:

– Маркетинг, пиар өлкәсендә хет аз гына белеме булган кеше мондый нәрсәләрдән ераграк йөри. Чөнки бу өлкәдә бөтен нәрсә дә тиз үзгәрә. Бер уңышлы алым табыла икән, аны шундук диярлек бөтәннәр кабатлый башлый һәм бу алым файдалы булуыннан туктый, киресенчә, зыянга эшли башлый. Һәр уңышлы яңалыкның төп файдасын аны уйлап чыгаручылар һәм башлап кулланучылар гына татып кала. Бөтен кеше дә хатын яки ир алыштыруын, кем белән ятуын, кем белән торуын, кайчан һәм каян бәби алып кайтуын сөйли башласа, бу беркемгә дә кызык түгел. Хатын-кыз артистларның шулайрак кылануын күрсәң, ирексездән уйлап куясың бит инде, русча уйлыйсың: «Сначала определись кто ты такая: певица или девица…» «Девица» дию юньсез сүз әйтмәс өчен генә инде. Хатын-кызны чәйнәп утырган ир дә хөрмәт уятмый. Кеше алдында түгел, хәтта үзара сөйләшкәндә дә гарип булып күренә торган нәрсә бит инде. Татарның менталитетына да туры килә торган әйбер түгел. Бездә азгынлык юк, дип әйтә алмыйм. Әмма бездә аны прилавкага куймыйлар.

Иҗат кешеләренең үрнәк булуын күрәсе килә инде ул. Тату гаилә, мәсәлән, намуслы кеше… Үрнәк үк булмаса да, хет гыйбрәт итеп мисалга китермәслек булсын иде. Мин иҗатчы тормышта бер төрле, сәхнәдә икенче төрле булсын дигән караштан ерак. Ләкин бит сәхнә – аерым, кием алыштыру бүлмәсе – аерым, бәдрәф – аерым. Шулай итеп эшләгәннәр бит. Әгәр бөтен нәрсәне дә күрсәтергә кирәк булса, аның барысын да сәхнә уртасына ясап куярлар иде.

Мин инде тагын кабатланамдыр. Җаваплылык булырга тиеш. Иҗат кешесендә – икеләтә. Үз гамәле өчен җавап бирми яки җавап бирә алмый торган кеше ул кызганыч та, куркыныч та.

Ә шулай да көчле энергетикалы, үз фикерле, кабатланмас җырчылар сагындыра. Аларның күбесе бу дөньяда юк инде. Әмма көчле җырчылар бар әле. Ясалма шау-шулар кубармагач, алар әле читтәрәк кала бирә. Чөнки без ясалма дөнья белән мавыгабыз. Димәк, җаваплылык бездә – халыкта да зур. Әйдә, ясалмалык белән мавыкмыйк инде, үз башыбызны эшләтик. Алайса анысын да ясалмага алмаштырырга күп сорамаслар.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Ахыры. Башы 15, 22, 29 сентябрь, 6, 20, 27 октябрь, 3 ноябрь саннарында

Хөкүмәт атлы карак. Калхузны талады, җирләребезне комсыз байларга өләште, мал-туарны суйды, техникасын каядыр апкитте. Кыскасы, авылны акыртып чишендерде.

– Дөрес, – дип җөпләде карчыклар төркеме.

«Тел остасы» аның саен шәбәрде:

– Шулай бервакыт телевизордан «Буран әбиләре»н күрсәттеләр. Безнең кай төшебез алардан ким, мәйтәм. «Буран»нар чит илләрдә буран уйнатканда ник без Сиерыбызны данламыйбыз, мәйтәм. Үлә бит авыл, мәйтәм. Әйдәгез, кымшаныйк, мәйтәм. Җыйдым кордашларны. Татай бит ул, энем Илдус, моңлы халык, борынгы көйләребезне сузганда, күз яшьләнә, юаныч та әле безгә җырулар. Боерса, атна саен клубта кәнсирт куярбыз, дибез.

– Кех-кех, кех-кех, – дип кеткелдәде арттан берәү. – Безгә залда өч кеше кул чабар микән? Кех-кх...

– Прәс, Гайфетдин! – Карт, борылып, кеткелдеккә йодрык янады. – Тик тор! Бик тә тирә-яктагы авылларда сәләтебезне күрсәтер идек, автобус юк, автобус! Район җитәкчесеннән ярдәм сораган идем, сезнең җырыгыз җырланган инде, мич башында сөякләрегезне җылытып ятыгыз, ди. Шуннан соң сүнгән идек тә, Фәзилә үсендерде. Әгәр, ди, ярышта алдынгылыкка чыксагыз, автобус сезнеке, тәэлешеп хет Кытайга барыгыз, ди.

Кеткелдек тагын аваз салды:

– Кех-кех! Директорда автобус кайгысы ди! Алдый! Аңа кәнсирткә китертеп, халыктан түрәләр сайлаттырасы бар! Югары прасинт өчен тырыша! Кех-кех!

Кирегә сукалаучыга берәү дә игътибар итмәде.

– Икенче соравың ни, энем Илдус? – диде карт.

– Әгәр дә сезнең белән янәшә яшьләр хоры да оештырсак, ни диярсез, җәмәгать?

– Ә монысы инде мәзәк! – диде Фәйзетдин карт, ә үзе көлмәде. – Ниткән яшьләр?! Югары сыйныфтагы барлы-юклы ун бала күрше руд авылына йөри. Татайча укып кеше булалмыйсың, янәсе. Ялган! Безнең Сыердан биш фән докторы, ике конструктор, өч журналист, унбиш мөгаллим, җиде галим, өч табиб чыккан. Барысы да татайча укыды. Миңа мәгълүм, хатын мәптектә хуҗалык мөдире иде. Бүген авыл яшьләргә корыды, энем! Һәммәсе шәһәргә кыяклый. Эш юк, эш! Хәзер оланнарны бәйрәмнәрдә генә күрәбез, оныкларны гүпчим күрмибез, җәйге каникулларда да кайтмыйлар. Сездә күңелсез, диләр. Ай-һаегыз юк, диләр. Алар бит тилифунга береккән.

– Вай-фай, – диде Мирзам.

– Алай ук арттырма инде, Фәйзетдин! – «Кыз»лар шаулашып алды. – Балалар гел хәл белешә. Ялларда капка төбе саен икешәр-өчәр машина әнә. Әле кәнсиртегезне тыңларга җыелабыз, диләр.

Егет култык астына кыстырган дәфтәрен Фәйзетдин картка бирде:

– Сыерда туып-үскән яшьләрнең исемлеген төзегез, без алар белән ничек тә аралашырбыз!

Кемгә нәрсә, кәҗәгә – кәбестә! Карт-корының аһ-зары Мирзамның йөрәген әрнетмәде, чөнки үзенеке – үзәктә. Ул Җиргә бердәнбер максат белән инде, аңа вак-төяк проблемалар белән күмелергә ярамый иде.

– Җәмәгать! Тынычланыгыз,– диде ул, аның бөтен уе тизрәк теләгенә ирешү иде. – Репертуардагы җырларны берәр-берәр куплет җырлап карыйбыз. Кайсыгыз гармунда уйный?

– Хәмит, түлке ул атнадан артык безгә катышмый, – Фәйзетдин карт гаепле кеше сыман башын аска иде. – Орышкан идем мин аны җиңелчә генә, көйне бозма, дип. Үпкәләде Хәмит.

– Ә без аңа ялынмыйбыз, авыз гармунын сыздырабыз, әйеме, кордашлар? – Кеткелдек Гайфетдин «ләләә» дип такмаклаган иде, аңа «нә-нә», «лү-лү»ләр кушылып, «оркестр» уйнарга тотынды. Егет авызының зур икәнен дә онытып, чәчрәп көлде.

– Җәмәгать, үтерәсез! Гармунсыз булмый. Хәмит өендәме?

– Саумысыз, туганнар?!

– Сау, сау, дуктыр диярсең! – Хәмит банкадагы тәгамен чирәмгә бушаткач, берсен алып тәмләп кенә суыра башлады. – Нинди культурный безнең Зөбәрҗәт кияве, ә! Элек без аның өчен хайван идек, инде дә туганнар икән. Алдакчы син! Дустыңның туенда төн ката гармун уйнаттың, сукыр тиен түләмәдең! Кит, суга бәрәм, кабахәт!

Егет «игезәге» белән шакгый чиләнәчәк иде.

– Гафу ит, туган. Мин – Илдус, яңа гына билгеләнгән сәнгать җитәкчесе. – Тизрәк акланмасаң, эш харап, Хәмит җиңен сызгана иде.

– Ә-ә, шулаймыни?! – Гармунчы кулын чалбар балагына сөртте. – Балык исе сасы. Син дә гафу. Күрешик! Ни йомыш соң, җитәкче?

– Сине эшкә чакырам, туган.

– Кая?

– Күл буенда балык тота. Хәзер дә шунда ул! – диде Фәйзетдин карт. – Җайласаң, майласаң, шәт, үпкәсе эрер.

Кинәт залга өермә төсле жуылдап бер хатын килеп керде.

– Аңгыра сарык-кәҗә көтүе! Сез монда бәкелдәшкәндә җирләребезне сатып, үзебезне батрак итәләр! – дип акырды ул. – Гылава белән Әнәс оныгы кырлар карый. Мәгәр ач күзләрне буклы себерке белән кумасак, пазур безгә, пазур!

Халык уптым ишеккә ташланды. Фәйзетдин карт кына усак ботагыннан юынган таягына таянып калды.

– Һай, һай, бу Санияне! Кеше котыртырга дисәң, аңа куш. Чебеннән фил әвәли. Басуларны чүп басты, Әнәс оныгы сөреп, бодай, арыш чәчсә, шөкер дияр идек әле. Саниянең бабасы Насрый фетнәче иде, диләр. Тирестә казынган күрше тавыгы өстеннән дә жалу язган, диләр. Нәсел чире! Монысы, Әмирҗан белән без – камунислар, дөреслек өчен көрәшәбез дип, күкрәк кага. Минем ише гади халык болай да дөрес яши, син бик кыю икән, хөкүмәт йорты каршысында кычкыр! Кая, эт чаба дип, бет чаба дигәндәй, мин дә түләүсез тамашаны багыйм әле, – дип, карт та ишеккә табан титаклагач, Мирзам уфырды. Бүген бер төрле, иртәгә икенче төрле, адәм баласының ыгы-зыгылы тормышында ни тәртип, ни мантыйк юк, мондагы хәлләр акылга сыймый иде. Ул Хәмитне эзләп күлгә китте. Күңел тагын алгысынды. Куе камыш белән каймаланган күлдән егет Айлиягә дип төнбоек өзә иде... Әллә табигать картая, әллә кешеләр чүп-чар ыргытып бызырдата, каракучкыл төстәге су, савытыннан түгелгән сыман, саеккан да иде. Алда зур һәм бәләкәй баш шайләнде. Зурысы ике таш уртасына консерв банкасы утырткан, шырпы сызып, шуның астындагы йомычкага ут элдертә иде. Кечкенәсе:

– Әти, чи бит инде маймыч, ашама! – дигәч, зурысы:

– Күзе бүлтәйсә, пешкән санала, улым, – диде.

Мирзам тамак кырды. Аталы-уллы аңа табан борылды.

– Клубка.

– Анда нәрсә онытгым икән мин, җитәкче?

– Синсез без көйсез, моңсыз, туган.

– Әһе, тиле ди мин! Карт-коры белән нервы туздырам, ди. Тегеләй уйна, болай уйнама, имеш.

Мирзам үзендә бер кимчелек тапты: ул ялына да, үгетли дә белми, чөнки Центаврда андый гадәт юк иде. Хәмит яхшысынмады, ахрысы (кешенең үтенечен аяк астына салып тапта әле син!):

– Гармунчыга үтереп мохтаҗ икәнсең, минем олы малай Фәнил ялда, ул да шәп сайрата. Безнең йорт яшел капкалы, авыл кырыенда ук, бәрелеп уз, – диде.

Фәнил капка төбендә утын яра иде.

– Ни хәлләр, дустым Фәнил?!

Ят адәмнең исемен атап сәламләвенә аптырамаган егет балтасын түмәргә чабып, сынын турайтты.

– Аллага шөкер, абый. Әти кесә телефоныннан зеңгелдәтте инде, абый.

– Миңа эш җиңеләйгән икән, Фәнил.

– Озын сүзнең кыскасы шул: минем вакытым тар, абый.

– Әтием, ялда, ди.

– Нинди ял? Йөз илле чакрымдагы Каган шәһәрен көненә икешәр тапкыр урыйм, абый!

– Аңламадым, Фәнил?

Егет әче әрем суы эчтемени, йөзе җыерылды.

– Дөнья шаулый бит, абый! Айдан төштеңме әллә соң? Бездә коточкыч фаҗига! Татайның телен кисәләр. Без, яшь милләтчеләр, моңа протест белдерәбез. Чиратлашып, шигарь күтәреп, хөкүмәт бинасы каршында таптанабыз!

Мирзам авызында телен әвәләде. Исән, киселмәгән... Фәнилдә дә ул исән, юкса кайнарланып сөйләмәс иде.

– Нинди кансызлык! Юлбасарлар шулай кыланамы? Хөкүмәт сакчылары нишләп халыкны якламый? – диде ул, аның мие түнеп кызган, тимер белән өткәндәй маңгае яна иде, Фәнил сүз белән «пешереп» аны тагын да кызартты:

– Ниткән юлбасарлар, абый кеше! Син, чын, сукыр һәм чукрак икән. Тулаем татайның телен кисәләр. Рудиядә шовинистик хәрәкәт көчәйде, илдә бер генә милләт, бер генә тел, бер генә дин дип бугаз ерталар. Бүген татай үз җирендә килмешәк! Колныкыннан да яман аның хәле! Безгә сары чәчле марзалар: «Өегездә генә үз телегездә бытбылдагыз, сез бердәм һәм бүленмәс Рудиянең нигезен какшатасыз», – дип югары мөнбәрләрдән төкерек чәчә башлады. Ә син монда гармун шыгырдатырга чакырасың! Җырлап-биеп кенә татайның исән калуы икеле, абый кеше!

Фәнил түмәрдән балтасын йолкып алды. Утын пүләне шартлап урталай ярылды. Гәрчә, дорфа сөйләшсә дә, Мирзам бу егетне ошатты. Менә кем яңа планетада хөр татай дәүләте төзеячәк! Батыр һәм гайрәтле, аннан битәр милләтем дип җанын фида кыла! Ул өмет белән өйалды ишегенә карады. Хәзер елмаеп Фәнилнең чибәр хатыны чыгар, әйдәгез, чәй эчәргә керегез, диер. Татай халкы кунакчыл ул. Монысы да Мирзам файдасына: әгәр яшь пар белән дуслашса, әлеге дә баягы әзерлек чарасына керешер...

Тик ишек ачылмады.

– Кайда эшлисең, Фәнил?

– Университетта укыта идем. Татай факультетын яптылар. Урам себерергә калмасак инде... Татайның киләчәге тузан белән өртелгән, абый.

– Гаиләң зурмы?

– Гаилә? Көлдермә, абый! Гомеремдә дә өйләнмим мин. Бу җәмгыятьтә балаларымны милләтеннән ваз кичтереп, манкорт итеп тәрбияләгәндә йөрәгемә кан савар.

– Дөнья киң вә широкий дип шаяртасыз... – Сез ди, сез! Без, бары тик без! – Әй, шаяртабыз. Каядыр күченеп яшәргә дә мөмкин, Фәнил, – диде Мирзам, тотлыга язып.

– Дөрес, дөнья киң. Татайны Рудиянең кайбер шамакай сәясәтчеләре күптән Магнолия далаларына куарга хыялланa. Ә мин фәлән төштә җәннәт, әйдә, дисәләр дә, туган җиремнән беркая да кузгалмыйм, шушында көрәшеп үләм.

Мирзамга кисәк кенә авыр булып китте. Гүя егет балтасы белән аның бөреләнгән өметен ваклап-тураклап ташлады.

Бая гына басуга йөгергән халык тыкрыкка җыелган, уртада яшь кенә ир заты аларга нәрсәдер сөйли иде, Мирзам да бер кырыйга килеп басты.

– ...Сыерда халкыбызның тормышкөнкүрешен сурәтләгән музей төзибез. Камыр ашлары пешерү цехын көйлибез. Күлне тирәнәйтәбез, балык үрчетәбез, алма бакчасын терелтәбез. Планда атлар фермасы, кымыз заводы...

ӘСӘР ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Төзәтмә

Газетаның 8 ноябрь санындагы «Татарстан бюджеты: беренче укылыш» язмасында «Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе Алексей Демидов» урынына «Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе урынбасары Альберт Вәлиев» дип укырга.
Хата өчен гафу үтенәбез!

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)

П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 16 ноябрьдә уйнатылачак бүләк –
5 КГ ШИКӘР КОМЫ

Бу атна җиңүчесе – Мөслим районы Мөслим авылында яшәүче Арсланова Мөнирә. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
ИТТАРТКЫЧ
МУЛЬТИПЕКАРЬ
ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

Әз-мәз мәзәк

– Ә син нинди кошлар яратасың?
– Кыздырылган тавык.

***

Мәхмүт бик уңайсыз көтүче булды. Сарыкларны санаганда, һәрвакыт йоклап китә иде.

***

Егет җиде юл чатында туктап калды. Зур ташка болай дип язылган: «Уңга барсаң, берни таба алмассың. Сулга барсаң, гомереңне югалтырсың». Менә шундый иде элек навигаторлар.

***

Әгәр сез асфальтка: «Лилия, гафу ит!» – дип язасыз икән, соңыннан ахырын да языгыз. Лилиянең гафу иткәнме-юкмы икәнен беләсе килә бит.

***

Психологка йөрүчеләр психологка йөрмәүчеләрне җиңәр өчен йөри анда.

***

Тузганактан кайнатма ясарга өйрәнгәнне ни өчен ташкабактан компот кайната белмибез?

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде



Беләсең килсә...

1 Бер елда ничә минут?
а) 252600;
б) 525600;
в) 626500.

2 Ван Гогның исеме:
а) Абсент;
б) Винсент;
в) Винарис.

3 Бу шәһәрдәге Чехов урамы нибары бер йорттан тора:
а) Омск;
б) Магадан;
в) Хабаровск.

4 Фәтхи Бурнашның тулы исеме ничек?
а) Фәтхенур;
б) Фәтхерахман;
в) Фәтхелислам.

Җаваплар: 1. б); 2. б); 3. а); 4. в).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: малай, тоткын, Того, карта, ЛОР, апара, дан, ул, ау, Зәй, әшәке, ит, Крылова, еш, бис, кара, Онегин, замана, Ли, ни, ашлык, ала, ач, шәм, БМВ, Буа, Янсуар, мәрмәр, ах, Озату, яз.

Вертикаль: Утрау, Борнаш, Плюшкин, Иләбәр, ятка, әрсез, Амур, карачкы, га, АМО, Мырау, ел, им, әз, ант, ойна, яра, Ив, наган, ат, Такташ, сау, Йолдыз, лабух, Гоа, әзер, лычма, Сорнай, Шарик, Враз.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 351

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+